# БАЙ УГЫЛЫ

## «Бай угылы»ның беренче басылуына мөкаддимә.

*Хөрмәтле укучым!*

*Җәнабеңезгә тәкъдим итдекем китабым бала вакытымда язылдыгы өчен күп йерләрендә косурлары бардыр. Шуның өчен сездән гаҗизанә гафуыңызны үтенәм.*

*Дөрест, ул косурларны ислях итү дә мөмкин иде. Ләкин, бердән, бала вакытымда язылган бер әсәремнән балалык фикеремне югалтасым килмәдекеннән, икенчедән, ислях вакытында романымның маэле югалачак булдыгыннан, иске косурлары, иске хәлләре берлән мәйданга куймак эстәдем.*

*Хөрмәтле укучым!*

*Яздыгым романымда бай угылларымызның тәрбияләре нинди идекене, вә бу тәрбияләрнең ни дәрәҗә зарарлы идекене укучыларымның күз алдыларына куймак эстәдем. Шуның өчен, сездән назыйры гыйбрәт берлән карап, Кәримнең һәммә эшенең, һәр хәрәкәтенең сәбәбене тикшереп укуыңызны үтенәм.*

*— Синнән Кәримнең ничек булуыны кем сораганы бар? Фатыйх байларың үз өйләрендә ябылып яткан гаепләрене кем мәйданга чыгарырга кушты? Үземезнең милләтнең гаебене башка кешеләргә күрсәтүдән ничек оялмадың?— диярсез.*

*Минем бу эшем, милләттәшләрем арасында бик күп вакыйгъ була торган мөдһиш бер хәлне язып мәйданга куюым, башка кешеләргә үз гаебемезне белдерер өчен түгелдер, кирәк бер кешенең булсын, кирәк бер милләтнең булсын, бар гаебене юк итеп күрсәтү яки яшерергә тырышу хәер хаһлык түгелдер. Чөнки бу эш шул кешенең яки шул милләтнең шул начар хәлендә дәвам итүене теләү буладыр. Билгакес, гаебене күрсәтеп, шуннан котылыр өчен юл күрсәтү хәер хаһлыктыр. Милләтемездә шул мәсьәләне ислях фикере уянмасмы дип, мин шул эшләремезне булдыра алдыгым кадәр*

*күрсәтмәк эстәдем.*

*Җәнабе хак һәрберемезгә хак фикерләр биреп, хәмияте миллиямезне уяндырып, ватанымыз, милләтемезнең файдасына тырышырга насыйп итсен!*

Мөхөммәд Гаяз.

**«Бай угылы»ның икенче басылуына мөкаддимә.**

*«Бай угылы»ның язылуында әллә никадәр кимчелекләр булса да, шул кимчелекләрне бетерү, төзәтү татар тарих әдәбиятына каршы җинаять булганга, иске хаталары, иске кимчелекләре берлән, үзгәртмәенчә икенче бастырырга карар бирдем.*

*Китапның унсигез-унтугыз яшьлек бер егетнең каләменнән чыкканыны онытмаенча, укучыларның бик нык тәнкыйть кылмаенча, ким якларыны кичереп, яхшы тарафларына карауларыны үтенәм.*

Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый.
1910 нчы ел, 14 нче июль.

Фатыйх байның өе кәефсез бер хәлдә иде. Чөнки бикә, дүшәнбә көннән бирле авырса да, һаман баласыны китерә алмаган иде. Казанның мәшһүр карчыклары һәммәсе монда иде. Хәтта төш күрүчеләре дә Фатыйх бай хатыны Сәгыйдә бикә берлән мәшгульләр иде. Өч көннән бирле, һәркөнне төрле карчык төрле төш килеп сөйләдеке кеби, һәркөнне мәхәллә хәзрәте дә зур кәгазьгә төшене һәм тәгъбирене язып йебәрә иде. Төшләр яхшы иде. Төшләрнең тәгъбире буенча, һәркөнне иртә берлән бала дөньяга киләчәк иде. Әмма өч көндә өч бала түгел, берсе дә туганы юк иде. Карчыклар да кулларыннан

килгән хезмәтләрене итүдә иделәр: ванныга да утырткannar, мунчага да керткәннәр, хәтта чүлмәк тә салганнар иде. Ләкин шунысы гаҗәп, бала һаман дөньяга килми, Сәгыйдә бикә авырганнан авырый иде. Әбиләр төрле киңәш итеп, «күз тиде бугай» дип, йеде мунчадан йеде таш, йеде корыган агачның ботагыннан йеде яфрак, йеде коедан таңга кадәр йеде төрле су, йеде кешенең йеде төшеннән йеде чүпрәк, йеде юлның чатыннан йеде үлән алып, шуларны яндырып, бикәне төсләделәр дә.

Бикәнең, озын авырудан хәле беткәнгә, һушы китте. Әбиләр бик куркыттылар, өйнең төрле почмагыннан: «Йә шәйхем, мәдәд, йә шәйхем, мәдәд!» — дигән тавышлар ишетелде. Бикәнең бу хәлене хәбәр алгач, бунда калган зур приказчик Мәкәрҗәгә, Фатыйх байга: «Бикә авыр, тизрәк кайт!» — дип телеграм да бирде. Әбиләрнең киңәше берлән мәдрәсәгә өшкерергә чәйнек керттеләр, шәкертләрдән өшкертеп алдылар; үзләре дә өшкереп, бикәнең өстенә шул суны сиптеләр, йөзләренә бөркеделәр.

Бикә азрак хәл алган кеби булды. Күзене ачты, каранды. Менә озак үтмәде, кисү башланды. Әбиләр тагы: «Йә шәйхем, мәдәд, йә шәйхем, мәдәд!» — дип, бик сузып-сузып әйтсәләр дә, бер дә файда булмады.

Сәгыйдә бикәнең бөтенләй үк гомере бетмәгәнгә каршы, хәл белергә үзләренең икенче йортларында тора торган Әхмәт учитель хатыны Сара килеп керде. Әбиләр Сарага баштанаяк эшне сөйләделәр. Сара бик кызганды, бик айады, ләкин бер эш эшли алмый!

— Акушерка китерергә кирәк, — дип әйтә генә башлаган иде, «йә шәйхем, мәдәд!» дигән карчыклар бердән:

— Ул нинди эш ул! Туган баланы марҗа кулына төшерү, ул ниткән сүз ул! Ул кайдан белсен ул! — дип, бик кычкырып орышырга тотындылар. Сара:

— Авыру янында талашырга ярамый! — дип, киенеп чыгып китте. Һәм туры ук барып, Сәгыйдә бикәнең җиңгәсе Зөһрә берлән киңәш итеп, акушерка да алып килде. Карчыклар төрле сүз сөйләмәкче булсалар да, Зөһрә дә бай хатыны булганга, авыз ача алмадылар.

Сара акушеркага һәммәсене бәйин-бәйин сөйләп бирде. Акушерка гаҗәпсенеп тыңлап торып, карчыкларны чыгарырга кушты. Сәхилә карчыктан башкалары чыктылар. Акушерка үз эшендә белемлегә күрә, озак тормаенча Сәгыйдә бикә баладан котылды.

— Ир бала бар, ир бала бар! Бикә котылды! Угылымыз бар! — тавышлары Фатыйх байның бөтен йортыны гөрләтте.

Кече атна көнне иртә берлән Фатыйх байны алырга пристаньгә атлар төште. Кучерлардан Фатыйх байны күрү берлән:

— Сөенче, бай! Угылыңыз бар! Бик сәламәт! — тавышлары бишалты авыздан берьюлы ычкынды.

Фатыйх бай өйгә кайтты. Өйдәге карчыклар һәммәсе: «Менә шулай иттек тә, шулай иттек», — дип, байга үзләренең хезмәтләрене сөйләделәр. Акушерканың килүенә байның кәефе китсә дә, приказчик:

— Хәзрәттән сорадык, ул «яраса да ярар шул» дип әйтте! — дигәч, эч пошуы басылды.

Сәхилә карчык баланың кендек әбисе булды. Озак үтмәде, Фатыйх бай, бик зур мәҗлес ясап, угылына Кәрим исемене куйдырды.

Сәгыйдә бикә сәламәтләнеп йетте. Фатыйх байларның тормышлары иске хәлене алды. Фатыйх бай кибеткә чыгып, Сәгыйдә бикә дә өй тәрбия кылу берлән шөгыльләнә башлады. Дәүләтләренең зурлыгы, бер-берсенә мәхәббәтләреңез дөрестлеге берлән, гомерләренең йемеше — балаларының сәламәтлеге берлән уздырган вакытлары иң рәхәт, иң сәгадәтле тормыш дияргә ярый иде. Тормышлары рәхәтнең эчендә булуы, киләчәктә рәхәтләре михнәткә әйләнү кеби эшләрне төшенү түгел, хәлләреннән зарланган кешеләрдән дә, кызыкка санап гаҗәпкә калып, көлүләренә сәбәп булган иде. Тәҗрибәсез яшь байларның гомерләренең көннән-көн рәхәткә әйләнүе, дәүләтләренең һәрвакыт алга баруы, эшләренең, сәүдәләренең һәрвакыт файдага булуы, тәрбиясез байларга дәрәҗәләреннән артык зур һавалар кертергә сәбәп булуда иде.

Кәримнең көннән-көн үсүе, матур тавышлар берлән сөйләргә теләүләре,

гомерләренә бала рәхәтләрене кушып, күрмәгән сәгадәтләрене калдырмау дәрәҗәсендә рәхәткә әйләндерүдә иде. Балалары да башта-күздә чибәр генә, төстә-биттә күркәм генә булганга, һәркемгә яраттырырлык килешлеге, нинди ата-ананы да сөйдерерлек гүзәллеге, нәрсә укыса да белерлек зирәклеге, ни өйрәнсә дә аңларлык фәһемлелеге булганга, шундый яшь байларның баласы булырга бик килгән иде. «Борыны курнос» дип кайсы кешеләр көлсә дә, икенчеләре «авызы кечкенә» дип мактый да иделәр.

Кәрим көннән-көн үскәнгә, тәрбия кылучының кирәклеге беленә башлаган иде. Яшь баланы тәрбиядән хәбәрсезлек, баланың бер генәлеге, тансыклыгы, гөнаһсыз баланың бара торгач ата-анасының бөтен рәхәтене югалта торган бер имгәк булуына сәбәп була торган эшләрдән булса да, надан байларның андый тәрбиятел-этфаль кагыйдәләрене ишеткәннәре дә юклыгы өчен, һәм ишетсәләр дә ышанмадыклары өчен: «Бер генә баламыз, рәхәт үссен!»—дип, урынсыз иркәләү, кадерләүләре баланы акыртын гына начар холыклар, ямьсез эшләргә өйрәтүләренә сәбәп булачак иде. Бала карарга кем булса да ярый дип, Кәримне тәрбия кылырга унөч-ундүрт яшеңдә Фәхри исемле бер малай алганнар иде. Фәхри баланы йоклатып, киендереп, башка кирәкләрне хәзерләп торганга, Кәрим бөтенләй Фәхригә ияләшеп беткән иде. Шуның өчен дә холыкларында икенче Фәхри булып бара иде... Чынлап исәпләсәк, Фатыйх байның дүрт-биш елдан ике асрау

малае булачак иде!..

Унөч-ундүрт яшенә кадәр атасыз-анасыз үскән, урамнан урамга садакачы булып йөргән, мәктәп бусагасына аяк басмаган, китап битенә күз ташламаган, дин белмәгән, дөнья күрмәгән бала берлән газиз балаңны бергә үстереп, бергә гадәтләндерү ни дәрәҗә файдасыз эш булса да, Фатыйх байлар малайны акчасыз торуына гына карап, файда итәмез дип beләләр иде.

Шул рәвешчә, Фәхри баланы һәрвакыт караса да, бикә дә бөтенләй башыннан ук таптамаган иде: ашату, эчертү, уйнату, көлдерүдә бер дә иренмәенчә карый иде һәм күп вакытларда хатын-кыз мәҗлесенә алып бара иде. Бала, нинди сүз сөйләсә дә, ни эш кылса да: «Юк, ярамый, бунысы ярый!

Шулай эшлә, болай кыл!» — дип өйрәтмәгәнгә, теләгән урында теләгән эшене эшли иде. Шундый яшь бикәләргә бердәнбер баласыны теләгәнчә кылындырмау шәфкать тә түгел!..

Кендек әбисе Сәхилә карчык та килгән саен баланың кәефене китереп, ата-анасыны сөендереп, үзенә бераз файда итәр өчен, кызыклы кыйссалар, гакылга сыймаслык әкиятләр сөйли иде. Гөнаһсыз бала — Кәримнең тәрбия кылучылары һәркайсы килгәнгә, һәрьяктан йетеш булып үсә иде. Сәхилә әбидән ялганчылык өйрәнеп, анасыннан һавалык, дорфалык гадәтене алып, Фәхридән әләкчелек, көчләүчелек, хәйләкәрлек, бозыклык өйрәнгәнгә, биш яшенә йеткәндә һәрбер әгъзасы бертөрле начарлык кыла башлаган кеби, татлы телләреннән дә әдәпсез сүзләр коела башлаган иде. Атасының, анасының асрауларга, хезмәтчеләргә кылган килешсезлекләреннән үрнәк алып, анлардан артыграк итеп асрауларны тиргәргә, сүгәргә, мыскыл итәргә башлаган иде. Бикә берлән байның, Кәримнең шундый эшләреннән шатланып, көлешеп торулары, Кәримгә тагы гайрәт китереп, көннән-көн дәресене алга гына йебәрә иде; Фәхри күңелгә тулмаслык эшләрне итеп-кылып күрсәткәнгә, һәр начарлыкны күреп үсә иде. Бикә буның һәр сүзеннән ләззәт алып, рәхәтләнеп торганга, бәгъзе вакытларда асрауларны сүккәч тә: «Бәгырем, балам!»—дип, авызыннан үбеп тә ала иде. Ник үпмәсен, биш ел элгәре истә юк баланиләр кыла?!.

Фатыйх бай бик юмарт кеше түгел иде. Алай булса да, Кәримнән бернәрсә дә айамаганга, теләгән нәрсәләрене алып бирә иде. Шуның өчен, Фәхри теләгән бер уенчыкны Кәрим алдырганга, бөтен заллары уенчык берлән тулса да, Кәрим яшьрәккә күрә, күгәрчен алырга котыртырга вакыт булмаганга, күгәрченнәре юк иде. Бара-тора аны да алдылар. Хәзер Кәримнән дә битәр, Фәхринең эше җайланды.

Әдәп өйрәтүче Фәхри Кәримне җәй көннәрендә бакчаларга алып йөреп, төрле уеннар күрсәтә башлады. Бара-тора бунларның барып мороз ашаулары, очраган кибеттән канфит алып ашап йөрүләре кирәк бер гадәт кеби булган иде.

Рамазан айларында Фәхри кәләвә (хәлвә) сатарга кызыгып, Кәримне

котыртып, кәләвә сатарга димләгән иде. Фатыйх байлар, Кәрим теләгәннең һәркайсыны кылырга тиеш дип белгәнгә, рөхсәт биргәннәр иде һәм Кәрим берлән Фәхри рамазан буена кәләвә сатканнар иде.

Замана үтә бара. Кәрим йеде яшенә дә йетте. Начар эшләре бөтенләй мәйданга чыгарлык вакыт булмаса да, «Бу баладан игелек күрмәсләр!» сүзләре ишетелә башлаган иде.

Фәхри берлән Кәримнең әрәм итүләренә Фатыйх бай биргән акча гына йетмәгәнгә, йетсә дә Фәхригә кесәгә салырга калмаганга, Фәхри, акчаны кулга күбрәк төшерер өчен, икенче бер хәйлә тапкан иде. Шуның өчен дә, беркөнне «Аркадия» бакчасына баруны бер хәйлә итеп, Кәримне «Аркадия»гә» барырга котырткан иде. Кәрим, әнисеннән акча алып бармакчы булып, акча китерсә дә, Фәхридән: «Бу акча йетми шул!» — сүзене ишеткәч, Кәрим кәефсезләнеп: «Тагы әнидән сорыйм», — дип китә башлагач, араларында шул сүзләр башланган иде:

Фәхри: Юк, сорама! Үзеңнең акчаң юкмыни? Бай баласы булып торасың! Мин булсам, янымда әллә никадәр акча йөретер идем.

Кәрим: Әни бирми шул!

Фәхри: Шкафта-фәләндә генә юкмы? Минем барасым да килми, әллә бармыйкмы?

Кәрим: Бүген кызык булмыймыни?

Фәхри: Бик кызык була! Ут уены да йебәрәләр дә, акча йетми шул...

Кәрим: Фәхри абый, үзеңнең азрак акчаң юкмы?

Фәхри: Минем кайдан булсын?! Синең, бай баласы булсаң да, юк әле.

Кәрим: Мин әнигә күрсәтмичә генә алыйммы?

Фәхри: Белмим, барасың килсә алырсың! Кая икәнлекене дә белми торгансыңдыр ич син!

Кәрим: Беләм, шкафның югары тартмасында да, буем гына йетми.

Фәхри: Урындык юкмыни?

Бу сүзләрдән соң Кәрим: «Әй, белдем!» — дип залга кереп китеп, шкаф янына акыртын гына барып, урындык куеп, тартмасыны ачып, бер уч көмеш

тәнкә алып, Фәхригә китереп тә бирде.

Фәхри: Ничек алдың?

Кәрим: Урындык куеп.

Фәхри: Шкафны яптыңмы?

Кәрим: Яптым.

Фәхри: Урындыкны алдыңмы?

Кәрим: Шунда калды.

Фәхри: Бар, җүләр, урынына куй, әниең белер.

Кәрим: Инде йетәрме?

Фәхри: Әллә, йетәр дә инде. Бүтән вакытта алганда мондыйны алма, бу беленер, кәгазьләр арасыннан кызылларыны ал! Аннары ары, маржа сыны ясаган була, шунларны ал!

Кәрим: Фәхри абый, тизрәк барыйк инде.

Фәхри: Ул ерак шул, кайчанга кайтырмыз, әниеңнәр ачуланырлар.

Кәрим: Мин әнидән сорармын;

Фәхри: Бар, алай булса сора, аннан ары барырмыз.

Кәрим: Кайчанга кайтырмыз, дим?

Фәхри: Таң аткач, актык парахут белән.

Кәрим: «Ярый, алай булса»,—дип, әнисеннән сорап, Фәхри берлән Кәрим сәгать сигезләрдә «Аркадия» бакчасына да киткәннәр иде.

Парахутта барганда, болар арасында шул сүзләр сөйләнә башланды:

Фәхри: Кәрим, беләмсең, бу нәрсә?

Кәрим: Ник белмим, тәмәке.

Фәхри: Юк, «папирус» диген!

Кәрим: Фәхри абый, син тартасыңмы?

Фәхри: Ник тартмыйм, ул бик тәмле шул.

Кәрим: Йә әле, тартып кара әле!

Фәхри, шырпы алып: Син бикәләргә әйтмә тагын! — дип, кабызып тарта башлый.

Фәхри: Кәрим, төтене матур чыгамы? Кара әле, нинди килешле.

Кәрим: Тәмлемени?

Фәхри: Ай, җүләр! Аннан тәмле нәрсә юк. Мин бер дә чәй эчмәенчә шуны гына тартыр идем. Мә, суырып карыймсың?

Кәрим: Юк, ул авызны пешерә, кирәкми.

Фәхри: Ник пешерсен, кара әле менә, мин аны бу төшеннән генә кабам. Мә, кап!

Кәрим (ирексезләнсп кенә кабып): Бер дә тәме юк ич!

Фәхри: Эчкә таба суыр!

Кәрим: Аннан ары авызга төтене керә шул!

Фәхри: Аны чыгарасың, аның тәме дә шунда гына шул.

Кәрим (акыртын гына суырып чыгарып): Тәмле түгел ич!

Фәхри: Шулай тарта-тарта тәмләләнә ул, менә тагы тарт әле! (Кәрим тарта башлагач): Бу юлы тәмлеме?

Кәрим (Фәхринең күңеле булсын өчен генә): Тәмлерәк.

Фәхри: «Менә шулай тарт, тәмле дә булыр, кызык та булыр. Әллә нигә син бер дә бай баласына охшап тумагансың. Күрмисеңмени, бүтән бай балалары нинди расхутланып, теләсәләр ни эшләп йөри! Син шулай да йөри белмәгәч, әтиеңнең байлыгыннан ни файда?! Менә мин тагы берне кабызам, сиңа да кабызыйк, икәү тарткач бигрәк кызык була ул!» — дигәч, шундый сүзләр берлән икесе дә кабызып, бергә «Аркадия» бакчасына барып керделәр.

Кәрим бакчада һәркемнең тәмәке тартуыны күргәч, кешелек, гүя, шул тәмәке тартуда гына кеби булып китте. Шуның өчен ул да тәмәкесене кабызып, үзене «фидаи» дип белеп йөри башлады. Һәм дөресте дә, алты-йеде яшендә бер баланың тәмәке тарта белүе бик зур эш булганга, Кәримнең һаваланырлыгы да бар иде!..

Бераз йөри торгач, авызының әллә нишләгәнене белеп, Кәрим: «Фәхри абый, авызым әллә нишләгән, су эчәсем килә», — диде.

Фәхри: Аның артыннан су эчәргә ярамый.

Кәрим: Нишли?

Фәхри: Авызны уя.

Кәрим: Алай булса чәй эчик?

Фәхри: Чәй ярамый, дим шул.

Кәрим: Минем бик эчәсем килә шул.

Фәхри: Алай булса утырыйк, — дигәч, бер чәй эчә торган йергә барып утырдылар.

Фәхри әйберләр йөртүчене чакыртып, исерткеч китертте.

Фәхри (элгәре үзе алып эчеп, Кәримгә дә салып биреп): Эч!

Кәрим: Нәрсә соң ул?

Фәхри: Шәрбәт.

Кәрим (эчә башлагач): Бик ачы икән!..

Фәхри: Юкны сөйләмә! Тизрәк эч, авызыңны төзәтер; эчмәсәң әниеңнәр авызың бозылуыннан белерләр. Күп-күп кабып эч; ачылыгына карама!

Кәрим, кайткач әниләре белмәсен, авызы төзәлсен, дип эчсә дә, яшь баланың башына китеп, үзе теләп эчү дәрәҗәсенә йеткән иде.

Шулай итеп, исеребрәк, тәмәке тарта-тарта таңга кадәр бакчада үткәреп, өйгә кайтып киттеләр.

Кәрим бик соң кайтып йокласа да, үзе бик яшькә, бер дә эчәргә өйрәнмәгәнгә, башы авыртып, кәефе китеп, төсе бозылып, иртүк торып башының авыртуыны Фәхригә сөйләде. Фәхри: «Әниеңә белгертмә!»—дип, кичә калган нәрсәне эчергәч, Кәрим тәмам сәламәтләнеп йеткән шикелле йөри башлады. Кәримнең болай булуы Фәхри өчен теләгәнчә йөрергә форсат булганга, сирәк-сирәк, шулай йөри-йөри, Кәримне тартырга, эчәргә тәмам өйрәтеп бетерде. Шул юл берлән җәй буе йөрделәр.

## II

Йеремез өстендә түшәлгән хәтфә палас төсле үләннәр үзгәрүдә, үлән өстендә бизәкләп матур итәр өчен үскән чәчәкләр саргаеп, адәм баласына иң рәхәт бирә торган татлы исләр бетүдә иде. Матур кошларның сайрауларыннан моңлы, кайгылы тавышлар ишетелүдә иде.

Кояшның нуры йер йөзенә зәгыйфь кенә төшеп, икенче күренеш күрсәтеп, җәй фасылының бетүене белгертүдә иде. Кабан күле кояшка каршы ялтыравыклы, килешле күренештә булса да, ташланган йорт кеби, тантаналы бер хәлдән киткән иде. Адәм балаларында һава һәвәсләргә, кәеф, хозурларга вакыт үтеп, һәркайсында бер эшкә дәрт салынган иде: бәгъзесе сабак укырга, бәгъзесе сату итәргә, бәгъзесе һөнәр өйрәнергә хәзерләнеп йөрүдә иделәр.

Мәдрәсәләр, мәктәпләрнең эчләре-тышлары, кереп укыр өчен һәркемне кызыктырыр дәрәҗәгә китерелгән иде. Бакчаларда чәчәкләр булмаса да, яфраклар бөтенләй үк коелып бетмәгәнгә күрә, мәктәп бакчаларында аз-аз шә- кертләр күренә башлаган иде.

Казанның Зәңгәр мәсҗед урамындагы яңа мәктәптә биналарының гүзәллеге берлән башка өйләрдән аерым бер манзарә күрсәтүдә иде. Мәктәпнең капкасында «Беренче сентябрьдә җомга көн сабак башланасы» дип язылганга, бәгъзе кеше баласыны бирер өчен, бәгъзесе сабак баш- лануыны карар өчен, мәктәпкә килүдә иде.

Бунлар арасында безнең Фатыйх байның Кәриме берлән Фәхри дә ат берлән килгәннәр иде. Укучылар, безнең Кәримнең мәйханә ишекләреннән чыгып мәктәпкә килүенә гаҗәпләнерләр дә, гаҗәпләнсәләр хаклары да бар.

Ничек булса да, Фатыйх байлар сабак укыту, гыйлем өйрәтүнең кадерене белмәсәләр дә, башка байларга ияреп, шул өченче мәктәпкә йөртә башлаганнар иде. Фатыйх байларның бу мәктәпкә балаларыны бирүләре белмәенчә генә булса да, белгән дуст-ишләрене бик зур өметләргә төшереп, киләчәктәге бәлаләреннән котылуларыннан да шик калдырмаган иде. Һәм, шулай, яхшы гына укытсалар, Кәрим гакыллы, тәүфыйклы, әдәпле, булдыклы бер бала булачак иде.

Мәктәп тәрбиясе берлән Кәрим, элгәреге начарлыкларыны бөтенләй оныту гына түгел, кылган эшләренең начарлыкларыны да тәмам аңлап, дөньясына, ахирәтенә файдалы гыйлем алып чыгачак иде һәм Кәримнең таралган начар исеме дә бик тиз онытылачак иде.

Фатыйх байның гакыллы дустлары Фатыйх байдан да бигрәк зур

өметләр көтүдә иделәр. Бунларны бу өметләргә төшерүче — мәктәпнең програмының, тәрбиясенең яхшылыгы, моннан элгәре дә никадәр начар балаларның әдәпле, инсафлы, тәүфыйклы, эшлекле булып чыгулары иде.

Мәктәпнең эче-тышы бик матур булган шикелле, укыта торган мөгаллимнәре дә бик яхшы: галим, гакыллы, тәүфыйклы, укытырга оста кешеләр иде. Укыткан нәрсәләре дә мөселман баласына, мөэмин буласы кешегә иң тиешле нәрсәләр иде. Укытулары да бик низамлы булган шикелле, балаларны да кыйнамый-сукмый гына укыталар иде. Бунларның мәктәбендә бер айда балалар төрки танып, язуга өйрәнгәнгә, безнең Кәрим дә бер айдан соң бөтен халык алдында үзенең укый-яза белгәнене, аз булса да дин таныганыны күрсәтәчәк иде. Шул сәбәптән бу мәктәп, халык арасында бик данлыклы, бик мәшһүр булган иде.

Бәгъзе муллалар, үзләренең файдаларыны күзәтеп, бу мәктәпнең яхшылыгыны белә торып, халык арасында вәсвәсә төшерергә теләсәләр дә, халык һәммәсене белгәнгә, бу эшләре берлән үзләренең ялганчылыкларыны гына исбат итүдә иделәр.

Кәримгә элекке көннәрне сабакка килү авыррак тоелса да, мәктәптә иптәшләре күп булганга, хәлфәләр бер дә ачуланмаганга, сабакларыны белгәч яхшы сүзләр әйтеп, укырга кызыктырганга, бала бөтенләй сабак укырга дәртләнеп киткән иде. Шуның өчен балада көннән-көн дәрт арта барып, уйнамый, шаярмый торган, сабагыны белеп бара торган бер бала була башлаган иде. Бу мәктәптә укуыны да, язуыны да бергә өйрәткәнгә, Кәрим бераз яза, укый да белә башлаган иде.

Бер-ике атна вакыт үтеп китте. Иске гадәтчә, кечеатна көн Сәхилә әби дә килде, Кәрим дә мәдрәсәдән кайтты. Сәхилә әби, Кәримнең мәктәпкә йөрүене белеп, шул хосуста сөйли башлады:

Сәхилә: Угылымны сабакка йөртәсезмени?

Сәгыйдә: Әйе, Сәхилә абыстай.

Сәхилә: Үзем укытырмын дигән идем, ник миңа әйтмәдеңез? Мин аның кендек әбисе ич! Кил әле, балам, сабагыңны укытып карыйм әле, нәрсә

укыйсың икән.

Сәгыйдә: Әле бер-ике атна гына булды, белми торгандыр.

Кәрим: Беләм! — дип китабыны алып: «Бар, яз...» дип укый башлады.

Сәхилә: Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Тукта, бәбкәм, тукта! Бу нинди урыс китабы?!. Ник болай укыйсыз?

Кәрим: Шулай ич!

Сәхилә: «Ай замана, замана! Ахырзаман инде, ахырзаман! Әллә ниләр чыгардылар, укуны да боздылар, тагы ниләр чыгар икән! Әле шәһәрне сихер берлән яктыртырга дип сөйлиләр икән. Исмасам, койрыклы йолдыздан да курыкмыйлар... Ай, Сәгыйдә! Белүенә кызыгу кирәкмәс иде. Теләп булган, көтеп алган бердәнбер балаңның рәхәтене югалтып, кәефене бозып, айамаенча ничек йөртәсең?! Сезгә дә бала булганчыга кадәрле генә шул. Булгач, бер-нәрсәгә дә күрмисез, рәтле нәрсәләр укытсалар, тагы бер хәл иде. Сабак дип әллә ниләр укытып йөргән булалар. Хәлфәләре дә зур кешенең баласы түгел, ди... Имеш, анда тиз белдерәләр. Синең балаңа белү ник кирәк?! Ул мулла буласы кеше түгел ләсә?! Үз дәүләтеңез үзеңезгә йетәр. Ул белсә дә әллә ни эш чыгара алмас, бу елда укыган кешеләрдә бар усаллык! Әле Шәйхетдин хәзрәт Бохарада укыган булса да, ниләр эшләде! Бохарада укыганга да бер дә ышанырга ярамый. Сабак укыган кеше дөньяда яхшы тора дип алдаган булалар. Укымаганнар тора алмыйлар инде! Менә мин, әлхәмделиллаһ, хәреф танымаган кеше булсам да, өшкерү вә төкерү берлән дә дөньяны уздырам. Үзеңез тагы менә, ирле-хатынлы бер дә язу да белмисез дә, укытырга да, яздырырга да аптыраганыңыз юк ич! Дәүләт булса, бар да була!» — диде. Ахырдан: «Минемчә, анда укытуыңыз бер дә тиеш түгел, минем догамны аласыңыз килсә, укытмаңыз. Тагы, баруында-кайтуында ирекле булса иде... Сәгать сигездә барып йет! Баргач та уйнама! Сабагыңны гына укып утыр! Барганда-кайтканда әдәпле генә, инсафлы гына йөр, күргән кешегә сәлам бир, өйгә кайткач та этиең-эниеңнәргә сәлам биреп кенә кер, айларны да олуглап кына тор. Урамда малайлар берлән дә уйнап йөрмә, киемнәреңне пычратма.

Кайтканда-барганда әшәке сүзләр сөйләмә. Ул нинди такмаза ул! Зинһар әйтсәнә, Сәгыйдә, безнең заманада шундый барны-юкны өйрәтәләр идеме?! Сезнең заманда гына да юк иде, әле чыкты шундый нәрсәләр! Уф Алла! Зикерем дә бар иде, әле тик сүз иярә сүз чыкканга гына сөйләдем», — дип өзеп куйды, һәм: «Әле кайчан әлеп-би укыды соң?» — диде.

Сәгыйдә: Юк, Сәхилә абыстай, әле бер дә укытканнары юк шул, шуның өчен үземнең дә күңелем кайтып тора иде. Ярый әле син килдең.

Сәхилә: Ул нинди әллә нәрсәләр укыту, ник анларга әйтмисез?! Элгәре әлеп-би, аннан ары әбҗәд, аннан ары иман, аннан ары әптияк иҗеге укыталар. Югыйсә ул мәптек солул изид берлән укый торган микән әллә? Шул мәптек булса, былтыр җыен саяк-сандырак исләре киткән булып сөйләп йөргәннәр иде. Кешеләр алдында бөтен балаларыны тыңлатып күрсәткәннәр икән дә, бер елда йеде-сигез яшьлек балалар укый-яза беләләр, пәйгамбәрләр хәлене белгәннәр, дин таныганнар, Коръән укый беләләр, намазга өйрәнгәннәр, ул әдәпле, инсафлы, күргән кешегә бер сәлам бирәләр, бөтен халык исе китте, дип сөйләгәннәр иде, мин: «Йә, ул чаклы тиз укыгач, белүләре корысын, бәрәкәтсез белү», — дидем. Элгәре безнең заманада дүртәр-бишәр ел укысалар да, язу да танымыйлар иде дә, бик яхшы торалар иде. Мин үзем укымаган булсам да укыту рәтләрене беләм.

Сәгыйдә: Анлары бик дөрест, Сәхилә абыстай! Бүтәнчә уйласаң, тагы башкача, укытмый калдырсак, бик әдәпсез булмас микән соң, димез. Баламыз да шук кына, үзене шаярта да башладылар. Әле шул мәктәптә, укытулары безнеңчә булмаса да, бик яхшы инсафлы булып килә иде, — диде.

Сәхилә: Юк, Сәгыйдә, син ул эшләренә бер дә кызыкма! Ул бар да булыр, яшь вакытта азрак мутланмаенча да булмый. Дәүләтеңез бар, шаярса да аңар гына йетәрлек булыр әле.

Сәгыйдә: Бозылып китеп бик күп акча әрәм итә башласа, бик авыр булыр шул. Әнә, Зариф бай угылы бозылып китте. Шакир абзый сизеп алгач та мәктәпкә биргән иде, нинди юньле бала булып чыкты. Зариф байның Сабиры, мескин, эшләмәгән эшене калдырмаенча, ахырдан никадәр дәүләт бетереп,

йортларыны сатса да йетмәде. Элек икесе дә бергә бозыла башлаган малайлар икән. Әле шул, Шакир байның угылының туенда мескин Зариф бай искедәге дәүләтләрене искә төшереп: «Мин дә угылымны шул вакытта мәктәпкә биргән булсам, бу дәрәҗәгә калмас идем, хатын-кыз коткысы берлән баламны әрәм иттек, дәүләтне дә бетердек, бу көнгә дә калдык!» — дип еглап сөйли дигәч, безгә дә шул көн йетмәсен дип куркамыз шул.

Сәхилә: Йә, юкларны сөйләп утырма! Аллага тапшыр да туктат! Андый юк-бар сүз күп булыр ул.

Сәгыйдә: Ай, Сәхилә абыстай! Син шулай дисең дә шул, безгә бала шул, ничек булса да яшь вакытында тыеп кала алмамызмы димез. Ул бозылып китсә, безнең дәүләт кенә йетәме соң?!. Бөтен Казан халкы күз алдыңызда: күрәсез, бозыклык артында йөреп нинди байлыклар бетмәде, нинди хурлыкларга төшмәделәр, ул кешеләр дә тугандук бозылып дөньяга килмәгәннәрдер?!. Нинди булса да коткы берлән бозылганнардыр. Яшьлек берлән без дә баламызны харап иттек, бала карарга кем булса да ярый дигән идек, ул начар кеше бернәрсәгә дә ярамый икән. Чибәррәк малай алып тәрбия кылдырган булсак, болай бозыклыкка өйрәтмәс иде. Безнең Фәхри, шул, бигрәк начар малай булды. Тагы аны да гаеп итәр хәл юк, ул белгәнене өйрәтте.

Сәхилә: Сәгыйдә, соң инде нишләмәкче буласың? Анда такмаза укып кына җайга килсә ярый ла. Ул мәктәптә кырык ата баласыдыр. Анда нинди үрнәк алырга кирәк. Ичмасам, бар да сезнең шикелле бай баласы булса ярар иде.

Сәгыйдә: Үзем дә шунсыны бер дә яратмыйм шул. Оялмаенча безнең Кәримне каравылчы Әхмәт малае янына утырта, ди. Фәхри аркылы: «Безнең Кәримне үземезнең тудыклар Фәйзие янына утыртсын, безнең баламыз кеч-кенә әле, бет ияртеп кайта, ярлы малайлар янына утыртмасын!» — дип әйттергән идем, хәлфәләре: «Монда Фатыйх бай бикәсенең сүзе (програмы) берлән эш йөрми, зуррак үскәч та баласыны кадерләргә өлгерер, тагы, кадер-лисе килсә, баласының сабагыны белдерсен! Без сабак белгән кешене бик

кадерлимез»,—дигән.

Сәхилә: Анлар шундый юкны-барны укый-укый сүзгә остарып беткәннәр инде, аларга җавап таба алмассың. Синең балаңны да әллә нинди сүзләргә өйрәтә башларлар, Алла сакласын, бусы гына йетмәгән әле, тизрәк алырга кирәк иде. Әле мин үземезнең Шакирларга барган идем. Угыллары Әхмәтзакир шул мәктәптә укый икән, менә сүзгә чаяланган! Әллә ниткән китаплар укыган булып утыра. Мөселманча баскан да — урыс китаплары инде анлар. Әллә ниткән бер кәгазь бар, фал кәгаземе, дим, «Фәлән шәһәр бунда, төгән кала бунда, — дип, лыгырдап тора. Үзене дә бик кызык иттем: «Син барганың юк ич», — дидем. «Мин китаптан карап беләм», — ди. «Менә шуннан ачып әйт, Әстерхан шәһәре кая?» — дип «Бакырган» биргән идем, әкшәк килде, көлгән булды. «Ул «Бакырган» андый китап түгел, менә мин шул китап — «Җәгърафия»дан карап беләм»,—ди. Ышанаммы соң мин?!. Аллага шөкер, алтмыш сигез яшендә инде! Тагы: «Фәлән абыстай сезнең укуыңызны яратмый», — дигән идем, «Ул укымаган шул, кайдан белсен»,—ди. Кадалып бетсен иде шул укулары! Кая барсаң, шуны сөйлиләр, менә гөнаһ шомлыгы! Кайдан чыкты, тыныч кына тора идек, имгәк булды ласа! Балаларны аздырып бетерәләр инде, безнең Кәрим дә шулай булмасын, дим шул. Фатыйх байга әйтеп, тизрәк алырга кирәк иде. Укытасыңыз килсә, үземезнең мәхдүмгә генә бирерсез, аның шәкертләре алай әллә нәрсә белмиләр, юаш кына булалар. Ул үзе дә әллә нәрсәләр укытмый, баруы-килүе дә үзеңез теләгәнчә булыр. Бай баласы дип сезнекене кадерләп тә тотар иде.

Сәгыйдә: Мин әтисенә әйтим дә, алыйк ахырысы, — дигәч, Сәхилә тагы әллә никадәр вәсвәсә кылып, Сәгыйдә бикәне алырга бөтенләй күндереп йеткергән иде.

Сәгыйдә бикә үзеннән-үзе дә мәктәптән алырга, баласыны харап итми калдырырга тиеш дип белгәнгә, Фатыйх бай кайткач та Кәрим тугрысында сүз ачып, Сәхилә әбинең бер дә тиеш вә муафикъ күрмәвене сөйләде.

Фатыйх бай Кәримнең укуыннан хәбәрсез көенчә генә, бераз гаҗәпләнебрәк: «Ник яратмый икән?» — дигәч, Сәгыйдә баштанаяк, Кәрим

укый торган мәктәпнең ысулы җәдидә мәктәбе икәнлегене, анда укытсалар, Кәрим тиз белсә дә, әллә нинди нәрсәләр белеп, үткенләнү хәвефе булган шикелле, баланың баруы-килүе вакытлы булуы, балаларыны да бай балалары янына утыртмаулары кеби, Сәхилә әби сөйләгән гаепләрене сөйләп, ул мәктәптән балаларыны алу аталык-аналык күз карашыннан (ноктаи назарыннан) бик тиеш дип, икенче мәктәпкә бирергә гозер кылды.

Фатыйх бай, Кәримне алсалар Фәхри аздырып бетерер, әле исмасам, аның берлән бергә тора алмаганга, Фәхрине бөтенләй онытып, бераз ипкә килмәс идеме дисә дә, Сәгыйдә бикә бер сүз дә әйттермәенчә, Кәримне мәктәптән алып, Шәкый мәхдүмгә биргәннәр иде.

Шәкый мәхдүмнең укыта белмәве Кәрим кеби укырга дәрт салган баланың да күңелене кайтарырлык иде.

Кәримгә мәктәптән чыккач иркен булганга, сабак вакытына барып йетмәсә дә хәлфәсе орышмаганга, Фәхри берлән акыртын гына, иске вакытларыны искә төшереп, анда-монда барып утыра башлаганнар иде.

Сабакка бару Шәкый мәхдүм кашында гыйлем өйрәнер өчен, дин белер өчен булмаенча, кечеатна садакасы китерер өчен бер хәйлә генә булганга, Кәрим чәһаршәнбе, кечеатна көнне сабакта булса, аныңча һич зарары юк иде, һәм дөресте дә Шәкый мәхдүмнең максуды хасыйл була иде.

Кәримнең көннән-көн яше үстеке кадәр холкы начарланып, әдәпсезлегене, азгынлыгыны арттырып, ундүрт яшенә дә йетте.

Бу елдан соң Кәримнең тарихының иң гыйбрәтле вакыйгалары булганга, аерым баш берлән язмакчы булдым.

## III

Кәрим ундүрт яшенә дә йетте. Фәлсәфә берлән карасаң, Кәрим туган көннән бу вакытка кадәр ундүрт ел үтте дигән сүз генә булса да, бу ундүрт елда Кәримнең башыннан бик күп нәрсәләр кичкән иде.

Кәрим ундүрткә йеттем дип сөенә иде. Сәгыйдә бикә берлән Фатыйх бай

да, карап торган газиз балаларының шул яшькә йетүеннән шатланалар иде. Кәримнең ундүрткә йетүдән башка бер эше булмаганга, шатланудан битәр, Фатыйх байларга: «Баламыз бернәрсә белми, начарлыкларга да өйрәнә башлады, үзе ундүрттә», — дип хәсрәтләнергә тиеш булса да, безнең байларның гаеп күрә торган күзләре ят кешеләр гаебене генә күргәнгә, Фатыйх бай: «Фәлән кешенең угылы солдаттан качып калган, фәлән байның асравы чыгып киткән, фәлән мөәззин теге байдан алган фидиясене әрәм итеп бетергән», — дигән кеби сүзләр берлән, Сәгыйдә бикә дә: «Әсма бикәнең күлмәге бер дә күремле булмаган, Гайшә, энҗеле калфак эшләргә бирдем, өч йөз тәнкәгә төшә, дигән иде, иляһи мактанчыклар! Калфагыны күрдем, йөз тәнкәлек тә булмас. Минем ни чикле кием-салымым булса да, сөйләмим, анлар юк-бар киемнәре берлән дә мактанышып йөдәп чыгалар»,—дигән кеби сүзләр генә сөйләгәнгә, бунларның башлары да фәлән асрауның хәле, Гайшә калфагы, Камилә ыштанынннан бүтәнне уйларга бушамый иде.

Кәрим ундүрт яшенә йеткәч, һәрнәрсәгә башкача карый башлады. Бигрәк, Кәримнең хатын-кызга күз каравы башкарды. Чөнки Кәрим, бәлигъ булганга, анларга бине бәшәрнең бер кыйсеме дип, яки ирләргә дөньяда рәхәт бирешеп торыр өчен яратылганнар, һәммә кеше шунлардан үзенә бер иптәш табарга тиеш дип кенә карамаенча, һәр җүләрнең күңелен табар өчен яратылган мәхлуклар, дип карый иде.

Фәхри Кәримнең бу хәлгә килүенә бик шатланды. Чөнки Фәхри өчен сәфаһәтнең тагы бер юлы ачылган иде. Моннан элгәре Фәхри берлән Кәримнең «гулять» итүләре исерткеч-фәлән берлән генә иде. Фәхри буннан элек тә Кәримгә ялгыз эчеп утыруның бер дә мәгънәсе юклыгын сөйләп, кызлар берлән утырышырга кирәклегенә сөйләсә дә, һич аңлата алмаган. иде. Шуны да аңлата алмаган дип, сез тагы Фәхрине сүкмәңез. Фәхри буны аңлата алмаса да, Кәримгә башка бик күп нәрсәләр аңлатты: тартырга, эчәргә өйрәнү — барысы да Фәхри аркасында иде. Бунсын аңлата алмавы өчен Фәхрине гаепләргә дә ярамый, чөнки инсан нәрсәне кабил, шул нәрсәләрне генә аңлый ала.

Кәрим бөтенеләй яңа дөньяга чыккан кеби булды. Чөнки табигатьнең уйлап аңлый алырлык булмаган тагы бер нәрсәсеннән ләззәт ала башлады... Гомернең бу елларында Кәрим начарлыкларның һәммәсене таныган балаларның түгел, иң мәгъсум балаларның да холыкларында, табигатьләрендә, кылыншларында үзгәрүләр күренәдер. Хәтта шул елларда начар иптәшләр тугры килсә, баланың азып китүе дә бик йеңелдер. Чөнки бала гомеренең бу елларында балалык халәтене ташлап, егетлекнең беренче баскычына басканга, күңелләрендә башка төрле фикерләр уяна башлый, әүвәлге вакыты кеби, эшләрендә күчергеч иттереп балаларны алмаенча, егетләрне үрнәк итә башлый. Эченнән һәрвакытта үзенең бер эше тулмаган кеби күренә. Үзене-үзе аңламый, күңеленнән бер нәрсә эзли, ләкин ни эзләгәнен белми, атасы-анасы, йорт-йере, никадәр рәхәт булса да, үзене-үзе гарип төсле күрә. Хасыйле, иптәшсезлек буны йөдәтә, ялгызлык бөтенләй изә башлый. Бу вакытларда буның дуст-ише, ата-анасы иптәш була алса да, егетнең күңеле аның берлән дә канәгатьләнми. Чөнки аның эзләгәне — серләрне белдерергә, һәр сүзне сөйләргә ярый торган, хәсрәтен дә уртаклаша торган, рәхәтене бүлешә торган бер иптәштер ки, ирләр сыйныфына да мотлак кызлардан, кызлар сыйныфына да ирләрдән булуы мөнтәкыйзы табигатьтер. Бу елларында шундый кешеләрнең теләгәннәрен хасыйл итсәң, ягъни күңелләре теләшкән бер кыз берлән бер егетне бергә кушсаң, ни дәрәҗә мәсгуд булыр иде икән?!.

Ләкин бу яшьләрдә безнең гадәтемездә өйләнү-фәлән итү мөмкин булмаганга, егетләр гомерләренең бу вакытларын башка эшләр берлән үткәрәләр. Бу вакытлар егетләр, яшь кызларның кыл өстенә баскан вакытларыдыр, һәм, бу вакытларда мөхакәмә, уйлау кеби нәрсә булмаганга, бу яшьтәге кешеләр нуль хөкемендәдер ки, иптәшләренә карап йөриләр, иптәшләре инсафлы, тәрбияле бала булса, инсафлы булалар, тәрбиясез булса, начар булалар. Бу чакларында егетләрне саклар өчен бер нәрсәдән ләззәт алдырырга тиештер.

Руслар, төрекләр, башка Европа халкының балалары бу вакытларында

мәдрәсә парталарында укуда булганга, анларның бик азы гына мондый эшләргә бушыйлар. Әмма безнең балаларымызның иң күбесе бу вакытта «Тәкый гаҗәп»не хәтем кылып, мәдрәсәләрдән чәчәк сатуыны бетереп чыккан булганга, бунларның күңелене төшерерлек бернәрсә кирәктер ки, иң яхшысы романнар, хикәяләр уку, театр тамашаларына барудыр. Егетләр бу романнардагы кешеләрдән гыйбрәт алып, бердән, холыкларыны төзәтәләр; икенчедән, андый юк эшләр эшләргә вакытлары калмый, өченчедән, вакытлары булса да, бу хикәяләр, романнар сайәсендә бунларның вөҗданы үзләренә баш булып, үзләрене начар эшләрдән саклыйдыр.

Укыр өчен яңа чыккан хикәяләрне, фәнни рисаләләрне, тарих китапларыны ихтыяр кылырга тиештер. Бунлар адәмне тугры фикергә төшерәләр, һәрнәрсә хакында чынлап уйларга сәбәп булалар. «Фәттахетдин», «Сәид Баттал», «Мәгъриб зәмин»дә «Иран дигән шәһәрдә...» дип башлаган хикәяләр, «Гуҗ бине Гоньк», «Албасты», «Әбугалисина» кыйссалары адәмне мөбаләгале сүзләргә ышанырга, башларын чуалтырга, хак фикердән ерак булырга сәбәп булалар. Мондый кешеләр Печән базарыннан башка йердә сүз дә сөйли алмыйлар, сөйләсәләр дә һәммә кешене көлдерәләр генә.

Әмма безнең Кәрим, язу танымаганга, китап укый алмый иде. Театр дисәң, анда баргалый иде. Хосусән, декорациясе яхшы уеннарны ишетсә, бер дә калмый иде. Ләкин Кәрим күп вакытта уртадагы урындыкларга утырып, амфитеатр ягында кешеләр күпкә күрә, анда таба карап утыра иде. Ат кәмитләреннән, май кәмитләреннән бер дә калмый иде. Марҗа тимер чыбыкта йөрсә, Кәримнең кәефе бигрәк килә иде. Кибеткә кайткач, тирә-күрше бай угыллары да җыелып, Кәрим ораторлары булып, ни күргәннәрене, марҗаның нинди киемдәлегене, ничек андый чыбыкта йөрүене сөйләп, гомуми мөхакәмәгә салалар иде. Ләкин мескин Кәримнең бу театрга баруы да бай угыллары арасында тәмәке тарту төсле бер егетлектән саналганга күрә генә булганга, моннан да кәефе бер дә килми иде. Кәримнең кәефене китерә торган нәрсә — спиртлы эчемлекләр иде һәм дә хәзер Фәхринең актыккы дәресене дә бик яхшы аңлаганга күрә, сәфаһәт артыннан да йөри башлаган иде.

Кәрим, кулына каләм тотып язу яза белмәсә дә, үзләренең кибетче малаеннан, акча биреп, кызыл кара берлән чәчәкле кәгазьгә: «Әссәламе галәйкем, йа афзалы дәр хәтран!..» дип башлаган әллә ничә хат яздырып алган иде. Бу хатларны Сәхилә әби аркылы үзләренә килеп йөри торган карендәш кызларына яудыра башлаган иде. Иң әүвәле кардәшләренә, аннан соң олугракларына, аннан соң үзеннән кечерәкләргә йебәрсә дә, һичберсе кабул итмәгән иде. Белмим, ни өчен кабул итми торганнардыр?!. Югыйсә

Кәрим үзе чибәр егет ич! Кәримнең урамда тәмәке тартуын күргәч: «Фатыйх бай угылы эшкә кергән икән», — дип тә сөйлиләр ич! Бу бай кызлары Кәримнең бу булдыклылыгын, күрәсең, күрмиләр дә, ишетмиләр дә, менә җәфа! Әллә күрсәләр дә анларның аңар исләре китми микән?!

Кәрим бунларның бу эшләренә бик кәефе китте. Хосусән, үзенә ягыныр өчен алган пудра, помадалары, күз караларының бер дә сөйдермәвенә эче пошты. Фәхри берлән киңәш итешеп, Яңа бистәгә барып, бер багучы карчыктан Кәрим өчен Зәлал исемле бер карендәш кызларын сөйдермәкче булдылар. Фәхри дә Кәримгә үз хәлене сөйләде. Ул да күршедәге мирза асравын сөйдерер өчен, үзе генә булса да бармакчы булып тора икән. Ике «каһарман» бер-берсен аңлашкач, бер кичне фидаәнә бер кыяфәт берлән Яңа бистәгә киттеләр. Абыстайны күрделәр. Хәлләрене дә сөйләделәр. Абыстай икесен дә сөйдерде, кулларына бер бөти берлән өшкергән сагыз бирде; бөтине янга тагарга, сагызны сөйдергән кызның сачы берлән әүмәләндереп пичкә — утка ыргытырга кушты. Карчыкның сүзен, баш өсте дип, тутырачак булдылар. Чибәр генә хезмәт хакы — садака да бирделәр. Карчык, кул күтәреп озын гына дога кылып, әҗерен Әбуҗаһил рухына багышлады. Егетләр: «Хуш, әби!» — дип чыга башлагач, карчык: «Туктаңыз әле, бәхетеңезне карыйм!» — дип, кулына бер китап алып, бәхетләрене карады. Кәримгә: «Бай булырсың, өч хатын алырсың!» — диде. (Чөнки Кәримнең бай угылы икәнене белгән иде.) Фәхринең «морза асравы» дигән сүзеннән абыстай Фәхрине бер морза баласы дип белгән икән, аңар: «Зур морза булырсың!» — диде.

Икесе дә бәхетләрене дә белеп кайтып киттеләр. Хәзер эш Зәлалнең

сачыны алып, әби биргән сагыз берлән әүмәләндереп утка ягуда гына калган иде. Анысыны да эшләсәләр, Зәлалнең Кәримгә гашыйк булуында бер дә шөбһә юк иде.

Кәрим, вакытын табып кына, беркөнне ишрак намазыннан соң Сәхилә әбигә барып, акыртын гына эшне аңлатты. Сәхилә әби дә эшләргә вәгъдә куйды. Күп тә үтмәде, Зәлал үзенең сеңелесе берлән Фатыйх байларга кунакка килделәр. Кәримнең бәхетенә каршы, Сәхилә әби дә монда иде. Сәхилә әби Зәлалне аулакка алып, Кәримнең гашыйк булуын, буны бик сөюене сөйләде һәм, һәртөрле кыйссалар берлән, Зәлалнең дә Кәримне сөюе тиеш икәнене белгертте. Ике сүзнең берсендә: «ГыЙшык тоту — пәйгамбәрләр сөннәте, пәйгамбәрләрдән калган!» — дип, дәлилләр дә китерде. Зәлал, дөрест, сафдәрүн иде. Алай да булса, Кәримне сөю кайда, күргән саен чиркәнгәнгә, гөнаһ булса да, Кәримгә хат язмавын әбигә аңлатты.

Әби: «Ай, бала, харап булырсың, һаваланма, алар төрлечә кылындырырлар! Болай булмаса, дөньяның икенче хәйләләре дә бар, үзең ялынып йөрерсең дә, ул сиңа карамас. Минем сүземне тыңла, әйтәсе сүзеңне әйт! Менә рәхәтләнеп йөрерсез, аннан ары үзеңне алыр, гөрләшеп гомер итәрсез! Әле миңа Кәрим: «Болай гына калдырмам, яисә сөйдерәм, йә боздырам», — дигән иде. Мин генә бастырдым!» — кеби сүзләр берлән димләсә дә, Зәлал: «Әби, теләсә нишләсен, мин аның сүзене тутыра алмыйм!» — дигәч, карчык: «Ай, балам, харап булма!» — дигән булып, аркасыннан какканда арттан азрак чәчен кисеп алды.

Кәрим чәчне күргәч бик шатланды. Чөнки хәзер, буласы эш булды дияргә ярый иде. Чәчне бик тиз, сагыз берлән әүмәләндереп, утка яктылар. Кәримнең табигать башкарды, Зәлал артыннан ялынып йөрүдән үтте. Хәзер, багучының әйтүенә караганда, чәчне утка аткан сәгатьтүк, кызның күңелендә гыйшык уты сагыз януыннан кызу яна башлый иде. Шуның өчен ялынып йөрүләр Зәлалгә калачак иде. Кәрим һәркөнне Зәлалдән хәбәр көтәргә тотынды. Бер көн үтте, ике көн үтте, ай үтте — хәбәр килмәде.

Бу көннәрне үткәрү Кәримгә бик йеңел булмады, алай булса да, төрле

эш берлән вакытын уздырды. Анда-монда бара иде, көненә бер-ике мәртәбә Зәлалләр яныннан үтә иде. Ләкин бу эшеннән дә һичбер файда булмады. Бер ай эчендә нә хәбәр алды, нә Зәлалне күрде. Ярый әле шул арада бер кыз берлән танышканга, шуның берлән вакытыны үткәрә иде. Сәхилә әбигә киңәш итте. Сәхилә: «Зәлал сөйсә дә хат язарга хурлана торгандыр, «Мин әүвәл алмадым, инде ул алмас, мыскыл гына булырмын», ди торгандыр. Син аны үзенә күрергә кирәк»,— дип киңәш бирде. Кәрим дә, күп уйламаенча, Зәлалнең аталары читкә кунакка киткәч, бер кешегә әйтми, Зәлалләрнең йортларына барып качынды һәм, кич булып, дворник яткач, өй почмагыннан үрмәләп, өй алды тәрәзәсе аркылы Зәлалләрнең спальняларына керү уены корды. Бәхетсезлегенә каршы, менеп йеткәндә кулы ычкынып китеп, күрше еврей йортына эт янына барып төште. Эт «вау-вау-вау» акырырга тотынды. Кәрим, нишләсен белмәенчә, анда бәрелде, монда бәрелде, беркая китә алмады. Өйдән кешеләр чыгып, мех урларга килгән дип, тотып полициягә озаттылар. Кәрим төрлечә аңлатырга теләде, булдыра алмады. Полициягә алып киттеләр. Иртәгесене сорашып, Фатыйх бай угылы икәнене белсәләр дә, атасы килмәенчә чыгармадылар. Фатыйх килеп угылын алды, еврейгә барып, гозерләп, эшне судка йебәрмәделәр. Алай булса да, Печән базары халкы төрлесе төрле уйга чумдылар. Бәгъзесе: «Еврейларда асрау янына кергән», бәгъзесе: «Дөресте дә мех урларга кергән», — диделәр. Әмма Кәримнең дуст-ише бер дә курыкмаенча: «Зәлал чакырган!» — дип, гаепсез кызның исемен сатарга тотындылар.

Бу вакыйгадан соң Фатыйх байлар берлән Зәлалнең аталары арасында дустлык, карендәшлек киселде. Кәримнең күңеле сүнмәсә дә, илтифат кылмаган булып йөри башлады. Дөрестене генә әйткәндә, Кәримнең Зәлалне сөйгәне, аңар күңеленнән һич гашыйк булганы юк иде. Бәлки кеше арасында сөйләгәнгә, бигрәк кибетчеләр арасында кызлар берлән йөрү, кызларны бигрәк харап итеп ташлау егетлектән булганга, Кәрим «сөям» дип йөри башлаган иде.

Зәлалдән өмет өзелгәч, Кәрим теге кыз берлән мөнәсәбәтен тагы тазартты.

Кәримнең яшьлегенең матур көннәре бер-берсе артлы килгән яшьлек тулкыннары берлән һәлакәт диңгезенә бер чумып, бер чыгуда иде. Шул вакытында ярдәмчесе дә Кәримне коткарырга тиешле урында, киресенчә, шул бәланең дәвамында ярдәмче генә була иде, чөнки аңар Кәримнең алган юлы үзенең дөньяда иң рәхәт эш дип белгән сәфаһәт галәмендә гомер кичерүендә бик зур сәбәп иде. Кәрим, кибеткә чыкканда да, приказчиклардан: «Эчмәгән кеше кешемени ул! Аның дөньяда рәхәте ни? Минемчә, гомер шул вакытта рәхәт үтә, берәр сөйгән кызың булса (бунын «сөйгән» дигән сүзе «мәхәббәт» мәгънәсендә түгелдер, бәлки, мөнасәбәте гайре мәшруга мәгънәсендәдер). Барып утырырга урының булса, менә мин шундый кешеләр яшьлекне «кызык үткәрдем» дисәләр, ышанам! Югыйсә, яшьлекне бер эш эшләмәенчә, укып-фәлән итеп үткәргән гомерләр гомер түгел! Яхшырырга өлгереп була, әмма яшьлек ике килми», — сүзләре Кәримнең димагының иң төбендә утырганда, Кәрим шул фикерләр берлән йөрүне яхшы һәм тиеш дип белә иде. Шуның өчен Кәрим, булдыра алган кадәре, шул юлда йөри иде.

Расхут акчаларына әүвәлрәк Кәрим бер дә аптырамады, чөнки Сәгыйдә бикә, «бәгърем йемеше» дип, ни сораса да һәрвакыт бирә иде. Фатыйх бай бу эшкә бик үк риза түгел иде. Чөнки бу акчалар, бу маллар Сәгыйдә бикәнең өйдә энҗеле калфак киеп утырып торуыннан җыелмаенча, Фатыйх байның маңлай тире берлән җыелганнар иде. Шулай булса да, Сәгыйдә бикә бердәнбер газиз баласыннан, ничек килгән булса да, үзенең малын кызганмый иде. Аныңча бу маллар дөньяда рәхәтләнеп, үзең теләгәнчә кылыр өчен генә бирелгән нәрсәләр иде. Югыйсә, бәгъзе җүләр байлар төсле, малыңны ярлыларга бирер өчен, яисә мәдрәсәләр салыр өчен бирелмәгән иде. Алай дигәч тә, Сәгыйдә бер дә фәкыйрьләрне кызганмый дип уйланмасын, кызгана иде. Ләкин аның кызгануы ярдәм кылу берлән түгел, «тәкъдир язган!» дигән сүз берлән иде. Сез, болай дигәч тә, садака-фәлән бирми дип уйламаңыз! Бирә иде, бирә иде. Бирмәенчә ярыймы соң?! Ул вакытта мәҗлестә һәммә хатын, кайсысы иренең тутасына бу ел сигез аршин ситса бирүене, кайсысы энисенең сеңлесенең кызына күлмәк-ыштан бирүене, кайсысы үзенең укыган

остазбикәсенә ярты кадак чәй бирүене сөйләгәндә, бу ни сөйләр иде? Ярлыга бирмәвен гаепләрлек тә түгел, чөнки ул акча, барыбер, сумага катышмаенча, Кәримгә китә иде.

Кәрим, бара торгач, моңар гына канәгать кылмый башлады. Акыртын гына әнисенең энҗеләрен, асылларыны сата башлады. Алай булса да, Сәгыйдә, читкә серне белгертмәс өчен, иренә дә әйтми иде.

Анлары шулай бер көе үтеп торганда, асрау кыз Миңлебикәнең корсагы булуы эшне бозды. Алай булса да, Сәгыйдә бикә бу эштә бик осталык корды. Кәримнең алай-болай исеме-чабы китмәсен дип, карчыкларны чакырып: «Асравымызның эченә җылан кергән, менә көннән көн арта, эче үсә бара»,— дип, дәва иттерә башлады. Әбиләрнең мөҗәррәб дарулары, ат тире дә файда бирмәде. Карчыклар да: «Гаҗәп бу, бикә, әллә җылан булмаенча, углан микән?» — дип, икенче төрле дарулар эчерә башладылар. Ләкин, мескинә Миңлебикә бу дарулардан тәмугъ газабы кеби авырлыклар чиксә дә, бер дә файда булмады. Сәгыйдә бикәнең бик ачуы килде. Асраугa да: «Баламны аздырып бетердең, йөзтүбән кит!» — дип, корсаклы кызны куып чыгарды.

Гаепсез кызның кая барасы билгеле инде... Күз яшьләре берлән... өенә барып керде. Күз алдыннан корсаклы кыз киткәч, Сәгыйдә дә иркенеләбрәк сөйли башлады.

Бу эштән соң Фатыйх байлар, уйлашып, Кәримне мондый эшләрдән туктатыр өчен, Фәхри берлән йөретми башладылар. Һәм озакламаенча Фәхрине куып чыгарып, Кәримне дә, кирәкле эш булмаганда, бер кая да чыгармый башладылар. Акча тугрысында да бик катылык кылырга тотындылар. Чөнки хәзер Кәримнең азуының сәбәбе — акча тугрысында иркенләтү икәнен аңлаганнар иде. Бу яшенә кадәр иркенелектә йөргән Кәримгә бу эш бигрәк авыр тоелды. Көн буе утырып торырга һич разый түгел иде, ләкин ни эшләсен, бер кая да китәргә хәле юк иде.

Ниһаять, Кәримне кысуларының очы чыкты. Корбан бәйрәме көнен Кәрим, әтисе биргән биш сум акча янына тагы әнисеннән ялынып-ялварып янә биш сум алып, дуст-иш берлән безнең бай угылларының бәйрәмнәрдә кәеф ача

торган йерләренә киттеләр. Дуст-иш арасында, сүз иярә сүз чыгып, Кәримнең этисенең байлыгыннан файдалана алмавын, һәм, болай ябылып яту егетлек түгеллегене сөйләп, төрле яктан Кәримне котырта башладылар. Кәрим дә, йеңелчә генә уйлап, бер эш чыгармакчы булып, өенә кайтып китте. Язмышка каршы, Фатыйх бай бәйрәм котларга киткән, Сәгыйдә бикәнең дә хатын-кыз ягында кунаклар берлән мәшгуль вакытына тугры килде. Кәрим, форсатны ганимәт белеп, бер дә уйлап тормаенча, шикәр балтасы берлән әнисенең сандыгыны  каерып, бар акчасын вә бриллиантлы йөзегене алып, чыгып качты һәм шул вакыттук баягы урынга барып, дуст-иш янына кереп, утыра да башладылар. Кәримнең акчасы мең сигез сум да ничә тиеннәр иде. Арадагы дустларның киңәше берлән, берсе китеп, йөзекне ломбардка салып, аны да акчага алмаштырды. Хәзер эшләр хозурланды: акча бар, иптәшләр бар, урын бар, кәефләрен йебәрә торган эш юк иде. Ләкин арадан берәве: «Фатыйх байлар бу эшне белгәч эзләргә чыгарлар», — дип, бу урыннан күчүне мәслихәт итте һәм күчтеләр. Арт-алны җыеп кына кереп, боларның мондалыгыннан бер кешегә дә хәбәр бирмәенчә, эзләргә кем килсә дә, кертмәскә кушып, кәефләрен дәвам иттеләр.

Фатыйх байлар бу эшне кич кенә белделәр. Шул сәгатьтүк приказчикларны йебәреп эзләтмәкче булсалар да, бердән, приказчиклар үзләре өйдә булмаганга, икенчедән, бу эшне халыкка беленүдән куркып, үзе кайтыр эле уе булганга, бу көнгә калдырдылар. Ләкин бу бәйрәм кич Фатыйх байлар өчен бәйрәм булмады — төн буе йоклый алмадылар. Иртәгесене дә, Кәрим кайткандыр уе берлән торсалар да, һаман Кәрим юк иде. Кичкә таба эзләргә кешеләр йебәрделәр. Төн буе эзләп, хәбәр китергән кеше юк иде. Өченче көнне Фатыйх бай, Казанның шул галәмен бик белә торган бер егетне чакырып, эзләргә үтенде. Ул да: «Баш өсте!» — дип, кичкә кадәр эзләсә дә, һичбер хәбәр китерә алмады. Фатыйх байлар бик гаҗәпкә калдылар.

Дүртенче көнне полициягә белгертеп, полициядән эзләргә үтенделәр. Аннан да файда чыкмады.

Печән базары халкына әүвәл кибет ачкан көнне сөйләргә бер вакыйга

булды, һәммә кибеттә дә Кәрим хакында берәр сүз сөйлиләр иде. Кайсысы: «Фатыйх бай үзе гаепле, яшь кешен ник тыярга тиеш!» кайсысы: «Сәгыйдә бикә ана була белмәде, угылы шундый булгач, акчасын да җыя белмәгән!» — дип сөйлиләр иде. Ләкин бу сүзләрнең берсеннән дә Фатыйх байларга һич файда юк иде.

Фатыйх байларның шундый кайгылы, нишләргә белми торган вакытларында, сугышып битләре җәрәхәтләнгән бер кеше килеп, Кәримнең түләп чыгарга акчасы юклыгын белгертте. Фатыйх байлар, бик тиз кеше йебәреп, алтын сәгатьләр берлән киткән Кәримне, күлмәкчән көенчә, сиксән сум түләп алып кайттылар.

Фатыйх байлар: «Эш болай булмый инде, өйләндермәенчә эшкә килмәс, өйләндерсәк, бәлки, эшкә килер, яше унсигезгә йетте!» — дип, өйләндерер өчен кыз эзли башладылар.

## IV

Кәрим унсигез яшенә йеткәндә кызыл йөзле, кара күзле, курносрак борынылы егет булып, төстә-биттә тәмам кеше кеби булган иде. Бозыклыклардан кылмаган эше калмаганга, начарлыгы берлән бөтен шәһәрдә исем тоткан иде.

Фатыйх бай никадәр эшкә кушарга теләсә дә, бердән, язу-сызу белмәве, бердән, ышанычсызлыгы өчен кибеткә дә чыгармыйлар иде.

Фатыйх бай һәр никадәр сәүдә итү тугрысында, сату-алу эшендә ялкаулык кылмаенча, төрле ярмаркаларга барып кәсеп итсә дә, Кәримнең әрәм итүе дәүләтләренә бик зур кимчелек биргән иде.

Фатыйх бай саранлыгы, тырышлыгы хакында бөтенеләй үк бөлгән исемене алмасалар да, әгәр Кәрим бу эшләрдән тыелмаса, бик тиз вакытта фәкыйрь булып калачакларыны белгәннәр иде. Кәримне ничек булса да

бозыклыктан коткарыр өчен, киләчәктәге бәлаләрдән сакланыр өчен бер эш кирәк иде. Ахырысыннан, Фатыйх байлар Кәримне өйләндереп, начар эшләрен ташлату уена килгәннәр иде. Кәримнең бигрәк азуына сәбәп тә хатын-кыз эше берлән ашау-эчү булганга, тәүфыйкланып китүе дә бик якын иде. Фатыйх байлар дуст-иш берлән киңәш итеп, уйлашып та, Кәримне өйләндерүне беркетеп куйганнар иде. Фатыйх байларның өйләндерүдән исәпләре дә кыз кирәклеге генә булмаенча, угылларын рәтләп, күңелен утыртырлык, Кәримне сүз берләнме, җай бердәнме, начар эшләрдән тыярлык бер иптәш тапмак иде. Андый кызны табуы бик җиңел эш булмадыгы шикелле, табылса да, бөтен дөньяга начар исеме чыккан, бозыклык берлән чабы киткән Кәримгә бирүләрендә сүз бар иде. Нинди ата-ана шундый егеткә кыз бирсен дә, нинди кыз ихтыяры берлән барсын?! Төптәнрәк уйласаң, Фатыйх байларның шундый әшәке, бозык, начар малайларына, үз файдаларыны гына күзәтеп, гакыллы, әдәпле кыз алып, аның бөтен гомерене әрәм итүдә кешелек күз карашыннан (инсаният ноктаи назарыннан) бик тиешсез эш булса да, безнең байлар үз файдалары дигәндә кешелек хакы түгел, мөселманлык хакын да ригая кыла торганнардан түгелләр иде.

Шул исәп берлән Фатыйх байлар анда-монда яучы йөртеп баксалар да, бер дә юньле хәбәр ала алмагачтын, бистәдән үзләренә ярарлык кыз таба алмауларын белеп, саладан, чибәррәк йердән соратмакчы булганнар иде. Һәм, үзе дә салада аны-моны белмәгән кызлар шундый бистә егетенә исләре китеп, кулларыннан килгәнне айамаенча, ничек булса да, игә китерергә теләүләрендә бер дә сүз юк инде.

Исәпли-уйлый торгач, дуст-иш диме берлән Зәй суы буенда Кыям тегермәнче кызына яучы куштылар.

Тегермәнче кызы безнең Фатыйх байларга бик ятыш кыз иде. Атасы-анасы тәрбиясендә генә үскән, сабак укып, эшкә өйрәнеп кенә гомерене үткәргән, әллә нинди назлылыкларга өйрәнмәгән, атасыннан башка ир заты күрмәгән бер кыз, Кәрим өчен җан бирер дәрәҗәгә йетеп, ничек булса да аны, шул эштән коткарырга тырышачак иде. Төсе-башы да: зәңгәр күзле, алсу

йөзле, кара чәчле булдыгы шикелле,татлы сүзле, йомшак күңелле, гакыллы, әдәпле, инсафлы бер кыз иде. Тирә-якта данлыклы булса да, гакыллылыгы, матурлыгы чаклы, чабы китмәгән иде. Дөресте генә, су буйларында, урманлыкларда үскән, матур һавада тәрбия кылынган бер чәчәк иде.

Ата-ана тигезлеге, тән сәламәтлеге, кул иркенлеге берлән үскән кызның холкы да, бер бозучы булмаганда, ни дәрәҗә яхшы булырга кирәк?! Кыям тегермәнчеләрдә холык бозучы кеше түгел, төзәтергә кирәк булса да табарлык түгел иде.

Кыз тугрысында эш калмаганга, Фатыйх байлар да ошатканнар иде. Шундый матур кыз булгач, Кәрим дә сөяр дип уйлыйлар иде. Кыз сөйсә тагы, Фатыйх байларча, Кәримнең сөюе бик кирәкле дә түгел, ул эшкә килсә, икенчене алу да бик авыр түгел.

Сәгыйдә бикә дә: «Әллә кем кызы рәхәт күрсен дип өйләндермимез, угылымыз азрак җайга килмәсме димез, тагы, сөймәсә, икенчесене алып бирермез!» — дип сөйли иде. Кыз тугрысында эш калмаса да, эшнең бик авыр йере — бирүләре, бирмәүләре иде.

Дөресте генә, Мәрфуга яучы төсле хатын ара йөргәндә ул тугрысында куркыныч юк иде. Мәрфуганың сүзләре дөрест булса, Кәримгә андый тегермәнче кызыны гына түгел, әллә нинди укыган кызларны да айарлык түгел иде. Ялганлый дияр идең, кулында тәсбих, телендә зикер, иртә намазлыкта, кич намазлыкта, хәзрәт сабагына кергән бер карчыкка ничек шул сүзне әйтергә кирәк?!

Кыям тегермәнче Фатыйх байны күреп тә белгәнгә, исемене һәрвакыт ишеткәнгә, бер дә курыкмаенча бирергә тели иде. Тегермәнче хатын Фәхриҗамал абыстай: «Кала төсле каладан Фатыйх бай угылына безнең кызымызны сорау ул ниткән эш икән? Монда бер-бер хикмәт юк микән?» — дисә дә, Мәрфуга абыстай андый эшләрне генә кермәгән яучы түгелгә, бер сүзенә мең җавап табып, Фәхриҗамал абыстайны да авыз ачарга урын калдырмаган иде. Мәрфуга яучы сөйләве буенча, бунлар кызын алырга теләүләренең сәбәбе дә — Кәрим гыйффәтле егет булганга, үзе төсле кызга

өйләнүдер ди генә иде. Күптән Кыям тегермәнче кызын ишеткәнгә һәм белгәнгә, шуны алыр өчен ата-анасыннан үтенеп, монда яучы йебәргән иде.

Фәхриҗамал үзеннән-үзе: «Фатыйх байларның, бунларның кызларыны алырга теләүләре банктагы утыз мең тәнкә акчалары барлыгыны белгәннәр дә, кирәк вакытта файдалана алмамызмы, дип уйлаганнар», — дип уйлый иде һәм, Фәхриҗамал абыстай, кияүләре яхшы булса, ул утыз мең тәнкәне дә бердәнбер кызыннан айамаска иде. Алай булса да, акча билетлары Кыям тегермәнчедә шул. Аның бирүендә-бирмәвендә сүз бар!

Алай уйласа да, болай уйласа да, Фәхриҗамал абыстай, кызының киләчәктәге бәхетсезлекләрен күргән кеби, булачак бәлаләрене белгән шикелле, күңеле бер куркудан котылмый иде. Мескинәне, ахыры, яучы алдады. Шулай итеп, колак сөенчесе алыштылар.

Фатыйх байлар туйны да бик зур иттеләр. Кияү дә керде. Инде көтәсе эш беткән шикелле иде. Фатыйх берлән Сәгыйдә бикә, анысын да бөтенеләй булган шикелле итеп куйганнар иде. Безнең Кыям тегермәнче берлән Фәхриҗамал абыстай да, ара-тирә сүз ишеткәнгә: «Баламызны харап итмәсәк ярар иде!» — дип, эчләреннән генә куркуда иделәр. Ахыр, нишлисең, эш бетте, туй да булды, кыз да китте. Фатыйх бай берлән Сәгыйдә бикә Кәримнең тәүфыйклануыны көтәләр иде, Кыям бабай берлән Фәхриҗамал абыстай да: «Баламыз гына харап булмаса иде!» — дип, догада торалар иде.

Килен өйгә дә килде, Фатыйх байларның көтә торган тынычлыкларының да вакыты йетте. Үз исәпләре берлән Кәрим, тәүфыйкка килеп, гакылга утырып, эшкә тотыначак вакыт йетте.

## V

Кәримнән изгелек көткәндә, әүвәл көндүк төн уртасына кадәр ашап-эчеп йөреп, исереп кайтудан башка файда күрсәтмәде. Фатыйх байларга хәсрәт арта бара. Әүвәле, исмасам, үзләре генә иде. Ни күрсәләр, үзләре күрәләр иде,

шуның өчен: «Нишлисең, үз баламыз инде, Алла тәүфыйк бирмәсме әле!» — дип, күңелләрене юаталар иде, хәзер киленбикә дә бар, аның ничек булуы бер хәсрәт иде.

Кәримнең әүвәл көндүк өйдә рәхәтләнеп куна алмавы киленнәренә бөтенеләй серне ачкан иде. Шул сәбәптән, Фатыйх байларның өендә бер кайгы, рәхәтсезлек падишаһлык сөрүдә иде.

Фатыйх байларның өендә иң кызганычы, иң хәсрәтлесе яшь килен Бәдрия иде. Мескинә Бәдрия нишләде?! Ана кулыннан чыкмаган, уналтыдан үтмәгән, тегермән шаулары берлән кәефләнеп гомерен үткәргән мәгъсумә кыз нинди хәсрәт, кайгыларга чумуда, нинди уйлар, фикерләр башыннан үтүдә икән?

Гөнаһсыз кызның килгән көне генә булганга, өйнең җаены да рәтләп белеп бетермәгән иде. Асрау исемнәрене, ашау-эчү тәртипләрене белмәгән шикелле, кибеттән кайвакыт кайтуларыннан да хәбәре юкка, Кәримне чын ихласы берлән, «тизрәк кайтса ярар иде» дип көтүдә иде. Өй эчендә сөйләшеп утырырга бер дә таныш кеше булмаганга, мавыгып утырырга эш тә булмаганга, үткәргән вакытлары бик хисаплы, минутлары берлән билгеле иде. Яңа кеше булганга, Сәгыйдә бикәнең дә холкын белмәгәнгә, яхшы күренер өчен роль уйнарга кирәк иде.

Икенде вакыты йетте. Бәдрия намаз укуы берлән үк кич булып, тәрәзәләргә караңгы төшә башлады. Асрау да, кереп, яшь бикәләрнең өенә ут алды. Бәдрия ут алынгач та киемнәрене алмаштырмакчы булса да, «Кәрим кайтып йетсә, каршы чыгып ала алмам» дип, тәрәзә төбенә утырып, пәрдә күтәреп, карап кына тора башлады. Урамнан кешеләр кайсы ат берлән, кайсы җәяү, бәгъзесе әйбер алып, кайсысы буш, эшле эшенчә үтүдә иде. Килен бикә Бәдрия дә, ерактан бер атлы күргәч тә, «Кәрим бугай!» дип, көзгегә барып, калфакларын төзәтеп, башын-күзен карап килсә дә, кайтучылар анлар булмагач, тегәп көткән кешесе Кәрим чыкмагач, эче пошып, читкә төшкән кеше кеби, оясыннан адашкан кош кеби, күңелләре кайгы-хәсрәтләргә урын булганда Аллаһе Тәгаләнең колларына мәрхәмәт өчен яраттыгы күз яшьләре,

Бәдрия өчен дә күңел ачарга, хәсрәтләр таратырга бик зур эш вә бик файдалы нигъмәт булган иде. Бәдрия, акрын гына сыгылып-сыгылып җылады. Әле күргән эшләре ул кадәр җыларлык ук булмаса да, атасыннан, анасыннан аерылган, ялгыз бер йергә төшкән, шундый дөнья күрмәгән кызның җылавыны да гаепләрлек түгел. Җылау берлән генә бәгыре басылмаганга, Аллаһе Тәгаләнең бәндәләренә дөньяда рәхәт бирер өчен, ахирәттә сәгадәткә ирештерер өчен тиеш кылган намазы да Бәдриянең кәефен китерергә, күңелен ачарга зур сәбәп булды. Күзләрене сөртеп, ахшам намазын кылды. Намазны тәмам кылгач, мескинә Бәдриянең Аллаһе Тәгаләдән ни теләве дә билгеле инде. Бәдрия догадан бушанганда урамда бөтенләй караңгыланган иде. Үтүче кешеләр дә күренми башлаганнар иде. Арба тавышлары да сирәк-сирәк ишетелә башлаган иде. Урам караңгылыклары урамдагы үтүчеләрне танудан тыйса да, Бәдрия, ничек булса да танырмын исәбе берлән, тәрәзәдән карауда иде.

Мескинә Бәдрия! Бәхетсез Бәдрия! Минуты бер сәгать, сәгате мең сәгать булып, үткән минут саен күңеленә бер җәрәхәт урынлаша иде. Кәримнең нинди рәвештә икәнлеген белгән булса да, әллә бу кадәр кайгыга төшмәс иде. Кыз катына кергәнчә, Бәдрия, Кәримнең холкын белү түгел, исемене дә белмәгән иде. Кияү булып торганда тәмәке тартуын белеп, элгәре бераз чиркәнсә дә, ирлек хакыны итеп, Кәримнең күңеле калмасын дип, анысыны да әйтми, Алла теләсә ташлар әле дип, күңелен бастырган иде.

Бәдрия, бер утырып, бер торып, йөреп тора иде. Ахрысы, аңар, ни булса да вакыт үтсен дә Кәрим кайтсын. Бер дә эш булмагач, вакыт үткәрәм дип, мендәрләрне ишеп, икенче мәртәбә өйсә дә, күңеленә тулмаган төсле булгач, өченче, дүртенче кат та өйде. Алай да килешсез булды. Ник алай булгандыр! Дөресте генә, Кәрим юкка һәрнәрсә килешсез иде. Аңсыздан асрау керде. Бәдриянең бөтен күңелендә Кәрим булганга, ул дип белеп, сикереп торса да, асрау икәнен белгәч, бер яктан кайгырып, бер яктан оялып, кып-кызыл булып китте. Асрау, сөйләргә башлап: «Бикә, абыстай ашарга-эчәргә чакырды», — диде.

Бәдрия: Әткәйләр кайттылармы?

Асрау: Әйе, абзый кайтты.

Бәдрия: Кәрим кайтмадымыни?

Асрау: Юк.

Бәдрия: Кая калды икән?

Асрау (белмәенчә): Ул тиз кайтмас әле, һәрвакыт сәгать уникеләрдә генә кайта.

Бәдрия: Ул вакытка кадәр нишли?

Асрау: Яшь кеше бит, анда-монда барып утыра торгандыр.

Бу сүзләрне ишеткәндә Бәдрия, салкынлы-җылылы булып китеп: «Бүтән вакытта да шулай йөримени?» — дип сорады.

Асрау: Күп көнне шулай итә, — диде.

Бәдрия, эшне аңлагач, мескинә килен, бәхетсез кыз: «Анадан ник тудым!» — дияр дәрәҗәгә килде.

Яшьлек рәхәтләрене күрә торган вакытында, баллы атналарында, дөнья күрмәгән бер кызның шул эшләрне күрүе, бөтен гомер буена рәхәт күрүдән өмет өздергән иде.

Асрау берлән гостиный залга керделәр.

Бәдрия каен анасына белгертмәскә теләсә дә, Сәгыйдә бикә Бәдриянең хәсрәтләнүен белгәнгә, үзе дә күңелене алыр өчен генә чакырткан иде. Бәдрия, каен анасының нинди холыкта икәнлеген белмәгәнгә, аз-аз гына сөйләп, Сәгыйдә бикәнең һәрбер эшен тикшереп, кылыншларыны карап, нинди холыкта икәнен белеп, аның холкы берлән гадәтләнеп, үзен якын күрсәтеп, үз анасыннан көткән өметләрен уйлый иде.

Мескинә Бәдрия бу уеннан файда итәр микән? Әллә мескинәгә бәхет ишекләре бөтенеләй капланган микән?.. Сәгыйдә бикәнең каен аналыгыны уйланса, каен аналарның киленнәргә дошман булу, зарар итәргә теләү фарыз дип белүләрене белсә, Сәгыйдә бикәнең зәһәр күзләренә авызына төшкән борыннарына, салынган кашларына караса, бу өметнең дә яңлыш икәнене белер иде.

Бәдрия, Сәгыйдә бикә берлән ашап-эчсә дә, күңелендә гел Кәрим генә иде. Бәдрия: «Кайда йөри икән? Кайчан кайтыр икән? Мине онытты микән?» — сөальләре берлән күңеле тулып, эче пошып эченнән еглап утырса да, Сәгыйдә бикәгә бер дә белгертмәскә тели иде. Сәгыйдә бикә, ул тугрыдан бер дә сүз чыгармаенча, башка сүзләр сөйләп, юатып тормакчы булса да, Бәдриянең күзләре гел ишектә, сәгатьтә генә булуы, бикәнең сүзләрене кайгылы кеше төсле генә тыңлавы Сәгыйдәгә киленнең хәсрәтләнүене белгерткән иде. Сәгыйдә бикә, Бәдриянең шулкадәр кайгыруын аңлагач: «Кайгы өстенә кайгы, бусы шулай җанымны кыйнар микәнни!» — дип, күңеленнән генә эче поша башлады.

Сәгать унбер дә булды. Кәрим юк. Өйдә һәр кеше ятып беткән иде. Бәдрия берлән Сәгыйдә бикә сөйләшеп утырган төсле утырсалар да, дөресте генә, берсенә берсе әйтмәенчә, Кәримне көтеп утыралар иде. Һаман кайтмый, һаман юк. Сәгыйдә бикә дә, эче бик пошып, чыдаша алмаенча, әйтмәс йереннән: «Әй бу бала! Кая йөри икән!» — дип йебәрде.

Бәдрия: «Әнкәй, кая икәнене белмисезмени соң? Бу вакытка кадәр нишләп йөри икән? Бөтен дөнья ятып бетте инде», — диде.

Сәгыйдә: «Аларның шайтаннары ятмаса ярый, әллә яхшылыкта йөри дип беләсеңме? (Ачуланып): Соң шул вакытка кадәр калырга оялырга кирәк инде, әүвәл киче бит!! Уф, Алла! Бозып бетерделәр баламны, харап иттеләр! Анасыны сәгать уникегә кадәр көттереп торырга оялырга кирәк иде. Ана ич!» — диде.

Бәдрия, Сәгыйдә бикәнең хәсрәтләнеп сөйләвеннән, айап: «Әнкәй, бар, ят син, мин үзем кайтканча көтеп торам»,—диде.

Сәгыйдә: Сиңа бик уңайсыз булмасмы соң?

Бәдрия: Булмас, әнкәй, бар, ят.

Сәгыйдә: «Ярый алай булса, мин ятыйм. Ул, кайткач, звонок тартыр, асрау хатынны уят та ул ачып кертер»,— диде һәм киленнең бераз күңелен табар өчен: «Кайтыр инде, кайтыр. Кайдан беләсең, әллә дуст-иш берлән утырышырга тугры килгәндер. Син бүлмәгә кер дә ятып тор!» — дип чыгып

китте.

Бәдрия үз өенә кереп утырды. Нә кеше бар, нә иптәш бар! Бары моңар иптәшлек итүче бер сәгать кенә иде. Ул да шундый вакытта озак йөри: бер минуты, әйтерсең лә, бер сәгать!

Бәдриянең күзләре кызарган, битләре саргайган, йөзләренә хәсрәт төсе чыккан, нишләргә белмәенчә гаҗәпкә калып тора иде. Мескинә бөтенләй уйга чумып, кечкенә вакыттагы кызыкларыны, тегермәндәге хозурларыны, әтисе-әнисенең кадерләүләрене, киявен матур, гакыллы, тәүфыйклы кеше була дип уйлап, дөньяда рәхәт торырга теләүләрене исәпләп, бу көнге очраган хәсрәтләрене фикерләп, киләчәктә тагы ниләр күрәчәкләрене исәпләп, бөтенеләй гакылсыз булу дәрәҗәсенә йеткән иде. Бәхетсез кызның гөл чәчәге төсле битләреннән мөлдер-мөлдер яшь ага иде. Күзеннән аккан яшьләр берлән күңелендәге кайгы-хәсрәтләре яшькә әйләнеп түгелгән төсле, эченең пошуының бетүенә, бәгъренең ялкынының сүнүенә сәбәп булу да иде. Бәдриянең күңелендәге дәртләр дә еглап кына басылырлык булмаган шикелле, күз яшьләре дә бетәрлек түгел иде. Бәдриянең һәрбер әгъзасында гүя бер хәсрәт бар шикелле, бөтен тәне берлән дерелдәп-дерелдәп еглауда иде. Су буендагы үскән йерләрене күз алдына китереп, Кәрим берлән ул кичәләрдәге тормышларын искә төшереп, ул вакытларны төштә күргән шикелле генә булып, дәхи икенче күрә алмауларын уйлап, яшьлегенең, матурлыгының файдасыны күрә алмавына гаҗәпкә калып, бер сәгатьне бер гомергә бирмәслек рәхәт вакытында шулкадәр хәсрәтләр, кайгылар берлән еглап торуын фикерләп, үксеп-үксеп җылый иде. Мескинә, Кәримнән җыласа да, Кәрим өчен хәсрәтләнсә дә, һаман Кәримне күңеленнән чыгармый: кайтса, күзләрем кызыл булмасын, яратмый башлар дип, дөньяга бирмәслек татлы җылауларыннан тыелып, көзгегә карап, күзенең кызыллыгыны бетерер өчен сөрмәләр тартып, яңадан киенде.

Звонок бар. Бәдрия, урынннан сикереп торып, чыгып, бик тиз ишекне ачты. Кергән кеше дә авыш-төеш килә, күзләре кызарган, җаны сасыган, лыбыр-лыбыр юкны-барны сөйли, баскычлардан таяна-егыла менә иде. Ул

кеше дә безнең Бәдриянең шулкадәр көткәне, җаны сөйгән Кәрим иде. Бәдрия, кулларын тотып, куәт биреп алып керсә дә, Кәримнең авызыннан Бәдриянең дөньяга килгәннән бирле ишетмәгән начар сүзләр чыгып тора иде.

Бәдрия мескинә: «Аргансың инде, ят!» — дип, урынга китерсә дә, Кәрим анда килеп, монда килеп, ава-түнә әйберләргә бәрелеп, шалтыр-шалтыр, сүгенеп йөрүдән туктамый иде. Бәдрия гомерендә мондый эш күргәне юк иде. Инде нишләсен? Ничек моны җайга китереп яткырсын? Ахрысы, барып, кулларыннан тотып: «Кәрим, җаным, бәгърем, әйдә, әйдә!» — дип, алып килеп яткырды.

Кәрим чыдыймы сон? Тагы торып китә башлады. Ярый әле, исереп куәте калмаганга, Бәдрия кулына асылынып яткыра алды. Авызы сасып беткән, йөзләре канаган Кәрим янында яту да Бәдрия өчен рәхәт төслерәк булган иде. Сөймәсә, ирекле көннән ятарлык түгел инде!

Кәрим, исереп арып беткәнгә, йокыга тиз китсә дә, йокы арасында әллә ниләр сөйләгәнгә, кайвакытта торып чыгып китә башлаганга, Бәдрия, ничек булса да бер-бер хәтәр булмасын дип, төнне йокламаенча үткәрде.

Иртәгесен Кәрим айныган иде. Бәдрия, төне буе йокламаса да, Кәрим сәламәт булгач, анысына гына разый иде. Кәрим, ул көнне дә «баш авырта» дип чыкса да, тагы шулай исереп кайткан иде. Беркөнне генә дә шулай калмаенча, һәркөнне шулай итүдә иде, ягъни искедәге кеби йөрүдә иде...

Бай берлән бикәнең өметләре хилаф чыкканга, Бәдрияне алудан чыгымнан (расхуттан) башка һич файда булмаганга, Бәдрия каен атасы, каен анасына зур гаепле кеше кеби күренеп, аннан үч алырга һәрвакыт хәзерләнүдә иделәр. Бәдрия, бикәнең тырт-пырт сөйләвеннән, күңелләре кайтканын бөтенләй аңлаган иде. Сәгыйдә: «Кәримне аздыручы килен генә булды. Үз ирен үзе тыя алмый!» — дигән сүзләрне ишеттергәч, бар куәте берлән Кәримне тәүфыйкка китерергә тырышмакчы булып, аулак вакытларда Кәримне кочаклап-кочаклап, күңел йомшата торган сүз берлән, болай эчеп-исереп йөрсә һәркем алдында кадере китүене, үзенең сәламәтлеге бетүен, исерек вакытта үзен-үзе белми әллә ни чаклы кадерсез итүене, бара торгач

бөтенеләй фәкыйрьлеккә төшүене, бу көенчә булса, рәхәтләре, дәүләтләре сүнүене җылап-җылап сөйләп, сөюе хакында, ичмасам акыртын-акыртын гына, өйдә генә эчүен теләсә дә, Кәрим үзенең аракысыны Бәдриядән дә сөйгәнгә, һәм Бәдриягә башка әллә ничә сөйгән фахишәләре булганга, һич ташлау уе юк иде.

Бәдрия, бер кермәсә бер керер дип, ничек булса да бу эштән күңелен биздерер өчен төне буе җылап-җылап сөйләсә дә, Кәрим тәэсирләнү түгел (гаебен сизү), йокысыны калдырган өчен ачулану берлән генә калмаенча, яныннан бәреп-сугып та төшерә иде. Бәдрия, моның кыйнау-сугуына да күңеле калмаенча, һаман җайлап сөйли иде. Кәрим аек вакытындагы үчен исерек вакытында исенә төшереп, Бәдрияне йозрык астларында да изеп бетерә иде.

Кызганыч Бәдрия, атасына-анасына хәлене сөйләсә дә, Кыям тегермәнчеләрнең дә аерып алудан башка имнәре юк иде. Бәдрия, яшь вакытта барган иреннән аерылып, башка кешегә баруны актыккы эш дип белгәнгә, күңеле сөйгән Кәримнән аерылып, башка берлән торырга һич разый булачак түгел иде.

Бәдрия Кәримне һәрвакыт ачуын китереп, борчып, үгет биреп сөйләп торганга, анасы да: «Хатының шундый, хатының мондый»,— дип сөйләгәнгә, Кәримнең барлы-юклы мәхәббәте дә суынган иде. Шуның өчен, исерек вакытларда, кайткач та элек эше Бәдрияне кыйнау, сугу, сүгү иде. Бәдрия кич берлән иренең кыйнау, сугуыннан, көндезен каен анасының талавыннан ялыгып, дөньяны бөтенеләй күрмәсә дә үкенемәс дәрәҗәдә күңеле кайткан иде. Һәрвакыт ялгыз калганда үзенең дөньядан шулкадәр җәберләнмеш булуына гаҗәпкә калып, хәйран булып тора иде.

Кәрим аз гына да тыелмады: һаман ашау-эчүдә, усаллыгыны, мутлыгыны көннән-көн арттыра баруда гына иде, Фатыйх бай берлән Сәгыйдә бикә, Кәримнең шул чаклы азуына Бәдрия генә сәбәп дип белгәнгә, угылларына икенче бер чибәррәк йердән хатын алырга тели башладылар. Шул исәп берлән анда-монда яучы кушсалар да, Кәримгә Казанда кыз бирергә

бигүк ашыккан кеше күренемәде. Бәдрия бу хәбәрне ишеткәч тә, ни эшләсен, каен анасына барып гозер кылмакчы булса да, бер файда да итә алмауны аңлады. Алай булса да, «Ятып калганчы атып кал!» дип, каен анасы янына кереп сүзгә башлады: «Әнкәем, бәгърем! Бер сүз сөйләмәкче булам. Сөйләүченең гаепләрен уйламаенча, сүзенә генә карасана!» — диде.

Шундый вакытта искедән бай булып килгән, киленнәргә рәхәт күрсәтмәскә тиеш дип белгән, һавалы бай бикәсенең ни әйтәсе һәркемгә билгеле инде: «Ни сөйләмәкче буласың? Сөйлә! Әллә, Кәримне аздырып бетереп, китәргә телисеңме?» — диде.

Бәдрия: Әнием, җаным! Алла сакласын! Андый һичбер уем юк. Бар теләгәнем дә — ярабби, шул эткәем-әнкәемә сәламәтлек, тынычлык берлән хезмәт итәргә насыйп ит, дип кенә. Минем сөйлисе сүзем, әнкәй, шул гына: мин саланың тегермәнче кызы гына, үзем дә салада гына үскән, бистә тәрбиясене дә күрмәгән, этиләр-әниләр дә прастуй кешеләр генә. Сезнең шикелле бай бикәнең килен булырлыгым булмаса да, безне кешегә санап алуыңызга бик рәхмәт, аның өчен сезгә һәрвакыт дога кылам. Үземнең кем икәнлегемне белгәнгә, сезнең килененез булуыма хурлану түгел, һәрвакыт мактанудамын. Нинди мәшәкатьле эш кушсаңыз да, баш өсте, дип эшләячәкмен. Угылыңызга хезмәт итүем дә күз алдыңызда — төне буе үгетләп йокламый ятам.

Сәгыйдә: Син дә үгетләргә ул синең балаңмыни?

Бәдрия: Нишлим соң, әнкәй, кулымнан килгәнне бер дә айамыйм да... Алла бирмәсә, булмый икән шул... Мин аны куркытып тыя алмыйм шул. Аның болай булуына хәсрәтләнүемне Аллаһе Тәгалә генә белә. Кайтса, кыйный, һичбер юньле сүзе юк, сүгүдән башымны чыгармый. Анысына да чыдар идем, бу эшеңез бик авыр тоелды, Кәримне өйләндерергә телисез дип ишеттем. Бераз тәүфыйкка килмәсме, дип уйлый торгансыз. Сәбәбе шул булса, әнкәй, зинһар мәшәкатьләнмәсәңезлә! Үзеңез миннән дә, расхуттан башка, файда булмады, дисез ич. Белмим тагы, Бәдрия бәхете берлән Фатыйма бәхете әллә бер булмас. Алай булса да, әнкәем, мине шул тугрысы берлән генә

җафаламасаңызла! Шул чикле тынычсызлык, кайгы өстенә угылыңыз берлән көндәшсез торуымны гына кызганмасаңызла! Мин дә, тегермәнче кызы булсам да, ата-ана баласы. Атам, анам минем дә рәхәт торуымны бик яратсалар да: «Кәрим эчә ул, холыксыз ул», — дип, аерып алырга теләмиләр ич. Әни, мине шул хәсрәтләр берлән дә көйдермәсәңезлә!

Яшь кыз булып килдем, әлхәмделиллаһ, атым-чабым китмәгән иде. Сала кызы булсам да, укыган да идем, эшкә дә өйрәнгән идем, ата, ана, ир хакын да белгән идем. Бер вакытта да эчемнән, тышымнан сезгә зарар итәргә теләмәдем һәм теләмәячәкмен. Килен булып төшкәннән бирле нинди хәсрәтләр чиккәнемне беләсез: һичбер көн исермәенчә кайтканы юк. Шулай булса да, аны да көйлим, сезне дә көчем йеткән кадәр кадерләмәкче булам. Шулкадәр җанымны фида кылып хезмәт итеп тә бу кайгыларга төшүемә гаҗәпкә калам... Аерып йебәрерлек яисә өстемә хатын алырлык ни гөнаһ кылдым икән?!. Үзең беләсең, әнкәй, синең дә яшь вакытың булгандыр. Мин быел төшкән килен, унҗиде яшьтә бер кыз әле. Үз башыңа шул эшләрне төшкән иттереп уйлап кара да, аннан ары, хәзер минем хәлем ничек икәнене белерсең! Үзем начар булсам да, атам, анам хакына шул кайгыдан гына араласана! Әнкәем, синнән башка сөйләр кешем юкка, оялмаенча сөйләдем, зинһар гаепләмә, ошамаган йерләрем булса, әйт. Синең әйтүеңнән һичбер хурланмыйм, бәгърем! Мине шул Кәримдә генә уртаклаштырмасаңызла! — диде.

Сәгыйдә бикә Бәдриянең шул сүзләреннән күңеле нечкәрде, Бәдрияне кызганды дип уйламаңыз, эченнән генә: «Үзәгеңә үтәмени? Синең шикелле шулай ... рәләр»,—дип, өйләндерергә тәмам күңелен беркетте. Бәдриянең йөрәге янганын белгәч, аны җылатыр өчен, аннан үч алыр өчен вакыт килгәнгә, кешелексез (инсаниятсез) каенананың күңелендә бер шатлык туды.

Сәгыйдә бикә каршысында Бәдрия бик гаепле булса да, дөрестлектә, бер дә гаебе юк иде. Бер дә кызганмаенча: «Өйләндерәм угылымны, моның берлән әрәм итеп тотмыйм!» — дип, чынлап ук яучы кушса да, Алла тәкъдиреннән узып булмый икән, яучы әйләнеп кайтырга вакыт булмады, икенче эш килеп чыкты. Бәдриягә теләгән усаллыклары өченеме, Сәгыйдә бикәгә гомер буена

хәсрәтләнерлек кайгы килде. Туй итәргә, кыз алырга, кеше җылатырга, Бәдриядән үч алырга вакыт калмады: Мәскәүдән бурыч өчен килеп, Фатыйх байларның кибетләрен пичәтләтеп, йортларыны язып, эшләрене туктаттылар. Фатыйх байларның бу эштән котылырлык акчалары булмаганга, бөлүләре беленгән иде.

Бу вакыйга Печән базарында бигрәк күп сүзләр сөйләргә сәбәп булды. Һәркөнне егерме, утыз төпсез хәбәрләр сөйләргә йолаланган (гадәтләнгән) Печән базары халкы эшне кырыкка дүндерделәр. Күбесе Фатыйх байның болай булуы да, башка Казан байлары төсле, акча басып калу дип уйласалар да, дөресте генә, алай түгел иде. Бәгъзеләре, Фатыйх байның русча киенеп йөрүеннән, бу эшне башкарыр әле дисәләр дә, Фатыйх байда андый эшләрне башкарырга кирәк нәрсәләрнең уникесеннән берсе булмаган шикелле, язу-сызу да белми, счетлары да карача гына иде.

Күрәсең, Фатыйх байның үткенелеге килен җәберләүдән башкага ярамый?! Фатыйх бай өч ай вакыт берлән акча табарга өстенә алса да, кайдан тапсын, анысы да күңел юатыр өчен генә иде. Өч айдан соң Фатыйх байларның кибетләре таратылачак, йортлары сатылачак булганга, искедән дәүләткә өйрәнеп килгән байларга бу көнне күрү бик авыр булачак иде.

Кәримнең исраф итүе ата-анасыны ахырында йортларыннан чыгарырга сәбәп булса да, Сәгыйдә бикә берлән Фатыйх бай аның бу кадәр начарлануына сәбәп Бәдрия генә дип beләләр иде. Дөресте генә, бу эшләргә сәбәп: Фатыйх байның дөнья рәтен белмәве, гыйлем кадерене белмәве, Сәгыйдә бикәнең бала тәрбиясендә хәбәрсезлеге, Сәхилә әбинең юк-бар сүзләренә ышанып, аның сүзе берлән баласыны мәктәптән алулары, Фәхри кеби мәктәп бусагасына аяк басмаган, китап битенә күз ташламаган, дин белмәгән, дөнья күрмәгән жулик малайга иптәш итеп, аның берлән йөртүләре иде.

Сәгыйдә бикәнең Бәдриягә каенаналык дошманлыкта булганга, бу эшкә сәбәп тә Бәдрия генә дип уйлаганга, бөлү кайгысыннан битәррәк үч ала алмау хәсрәте иде. Шулкадәр хәсрәтләргә төшергән, җан көйдергән, мал бетергән Бәдриядән үч алмый калу да бер дә ярамый!

Санаулы көн үтә. Фатыйх байларның вәгъдәләре дә тулды. Акча тапмаганга, йортлары да сатылды, кибеттәге мал да алынды, Фатыйх байны үз йортыннан үзене куа башладылар. «Әй, Раббем, ни гөнаһ шомлыгы! Бу көнне күрергә кем сәбәп булды?» Сәгыйдә бикә дә: «Бәдрия харап итте, Бәдрия!» — сүзеннән башка сүз белми иде.

Бәхетсез Бәдрия атасыннан, анасыннан, рәхәтеннән аерылды. Дөньяга килүенең кирәклеге, дөньяда торуның вакыты, рәхәт күрүнең заманы йеткәндә анасының йомшак сүзләреннән аерылып, Сәгыйдә бикә кеби зәһәр йоткан бер хатынга килен булды, Кәрим төсле, дөньясында, ахирәтендә рәхәт күрмәячәк, төне-көне эчүдән айнымаячак, күргән саен сүгүдән башыны чыгармаячак, очраган саен типкедән җанын чыгармаячак бер кеше берлән гомерен әрәм итәргә дә риза булды. Каен атасыннан, каен анасыннан, иреннән күргән начарлыкларга каршы да яхшылык итеп, акча ясар өчен җиһазларын, энҗеләрен, асылларын сатуны да бернигә күрмәенчә бирсә дә, аздыручы да, бөлдерүче дә ул булып калды.

Сәгыйдә бикә, башкача үч ала алмагач, көне-төне: «Дәүләтемезне бетердең, рәхәтемезне югалттың, сиңа каһәр суксын!» — дип, каһәр дога берлән шелтәдән айнытмый башлады. Бәдриянең уйсыз дустлары: «Өстенә көндәш алырга телиләр иде, менә алсыннар инде!» — дип, Бәдрияне шатландырмакчы булсалар да, Бәдрия галиҗәнаб (бәләнд, һиммәтле) бер кыз булганга: «Ирем эчмәсә, иске дәүләтемез кайтса, берне түгел, икене алса да риза булыр идем. Ул вакытта көндәшле булсам да, ирем дә булыр иде, дәүләтем дә булыр иде. Хәзер берсе дә юк», — дип җавап бирә иде.

Фатыйх байлар өйләреннән чыккач, егерме биш-утыз тәнкәлек фатирга кереп, вак-төяк калган акчалар берлән тәрбия кылынып тора башласалар да, акча бик тиз бетә башлагач, гарьләнә-хурлана гына булса да, ун тәнкәлек кенә фатирга чыктылар. Фатыйх бай элгәреге дуст-иш берлән акыртын гына эш итеп, бераз акча китереп тора башладылар. Кызганыч, Бәдрия нишләсен инде? «Буласы эш булган, исәпләп торып файда булмый», — дип, хурланмаенча кул эшенә тотынганга, эш, бердән, мавыгу булып, икенчедән, яхшы гына акча

китергәнгә, җыйнак кына өйне җыеп тотарлык файда була башлаган иде.

Фатыйх бай чибәр генә акча китергәнгә, Бәдрия дә кул ялы бик яхшы тапканга, акыртын гына баерлык эшләре булса да, Кәрим, һич файда китермәенчә, гел эчеп кенә торганга, бер дә арта алмыйлар иде. Сәгыйдә бикә, искедәге дәүләтләрене исенә төшереп, Бәдриягә бәддога кылса да, Фатыйх бай, Бәдриянең кул көче берлән дә никадәр акча тапканыннан килен бикәдә бер гаеп юк икәнлеген белгәнгә, күңелен алыр өчен «кызым, балам» дип кенә сөйли иде. Бәдрия үзенең яхшылыгының бер файдасыны күрде. Каен атасының чын күңеленнән ризалыгына әллә никадәр сөенеп, әнкәсенең дә бервакыт күңелен алырга тели иде.

Еллар үтте. Бәдриянең бер угылы да булган иде. Фатыйх бай, бусы да харап булмасын дип, һәрвакыт шул баланы гына тикшереп тора иде. Сәгыйдә бикә дә карчык булган иде. Кәрим дә иске эшендә иде: һәрвакыт Бәдрияне кыйнап-сугып, биш-ун тиен алып, эчүдә иде.

Гомер үтә бара. Фатыйх бай да карт кеше булды. Бәдрия дә яшь кызлыгын бетерде. Бәдриянең угылы Рифгать тә сигез-тугыз яшькә җиткән иде. Һәр эшләре шулай бер төрле җайланып, дөнья үткәреп килгәндә, Фатыйх бай үлеп, эшләре тагы чуалды. Бу эш Кәримнән башкалары өчен бик зур хәсрәт булды. Мескинә хатын Бәдриянең бөтен гомерен сарыф кылган, дөньясыны биргән, дөньяда шуннан башка рәхәт күрмәгән, «кызым!» дигән сүзене дә әйтүче калмады. Алай булса да, уйлаган кеби үк булмады: Сәгыйдә бикә бөтенләй инсафка килмәсә дә, Бәдрия бөтен җәмәгатьләрен карап торганга, тотып-тотып таламый башлады. Адәм баласы нигә гадәтләнми?! Бәдрия дә өй җәмәгатьләрене ялгыз гына туйдыра башлады. Алай булса да Кәримгә эчәргә акча бик аз арта иде. Рифгать тә зурая бара, мәктәптә бик яхшы укып, әнисенең тәрбиясе берлән, мәктәп өйрәтүе берлән әдәпле, инсафлы бала булганга, бик зур өметләргә төшерә иде.

Бәхет ишекләре бөтенләй капланган Бәдриягә төрле-төрле өметләр туа башлады: шулкадәр рәхәтләр, мәшәкатьләр күргән булса да, төшендә күргән кеби булып, хәзерге әнкәсенең дә инсафланып йетеп, «кызым!» дип кенә

сөйләве, Рифгатьнең дә бөтен яктан килүе, гомере буенча күрмәгән рәхәтләрен күрсәткән иде.

Бәдрия, рәхәт өстенә рәхәт килүенә Аллаһе Тәгаләгә шөкер кылуны һич онытмаенча, бар гомерене Рифгатене тәрбия кылуга гына сарыф кылып, шундый баланың анасы булуы өчен үзен дөньяның иң бәхетле хатын дип белгән иде һәм, шулай торса, Бәдрия күргән хәсрәтләрене дә бөтенләй онытачак иде.

Бәхетсезлеге бетеп бетмәгән икән: беркөнне Кәримнең кабакта (мәйханәдә) сугышып, иптәше үлеп, моның бик каты җәрәхәтләнеп больницага алынганлыгын белгерттеләр. Сугышның мәсьәләсе дә шул рәвешчә булган икән:

Гадәтенчә бар акчасыны эчеп йөри торган Кәрим, шул көнне мәйханәгә кереп, эчә башлагач, күптән бирле буның берлән бер «сатлык кыз» өчен тартышып йөри торган кеше кереп утырган. Андый кешеләр кылган начарлыкларының кылуыннан битәр сөйләүдән дә әллә никадәр ләззәт алалар. Кәримнең дошманы да, бердән, иптәшләренә мактаныр өчен, бердән, Кәримнән үч алмакчы булып, фахишә берлән үзенең ничек йөрүләрене, Кәримне кертмәенчә йебәртүләрене иптәшләренә сөйли башлагач, Кәрим оятына (намусына) чыдый алмый, сүгенергә тотынса да, Хөснинең иптәшләре күп булганга, буннан бер дә курыкмаенча торып бәйләнеп, кыйнаша, сугыша башлаганнар. Кәримне ни эләкте шуның берлән кыйный башлагач, Кәрим, кесәсеннән пәке чыгарып, Хөснинең эченә чәнчеп, Хөснине екса да, иптәшләре, кыйнап, моны да кешелектән чыгарганнар иде. Хөснинең иптәшләре үзләре бөтенләй сугышмаган булып, полиция алып кереп, Хөсни үләргә йеткәндә Кәримне дә бик авыр хәлдә алып китсәләр дә, больницага барып йеткәнчә үк Хөсни үлгәнгә, теге кешеләрнең сүзләренә караганда, башлап бәйләнүче, пәке берлән әчене яручы да Кәрим иде. Полициядә Кәримнең кесәсеннән пәке тапканга, Кәрим бөтенләй үтерүче булып калган иде.

Сәгыйдә бикә, Бәдрия, Рифгать, бу хәбәрне ишеткәч, башларыннан

салкын су койган кеби булып, нишләргә белми, катып калганнар иде.

Бәдрия, дөньяны белә башлаганнан бирле ачысыннан, төчесеннән татыганга, моның шикелле эш күргәне булмаса да, «Бу хатыннар башкара торган эш түгел» ,— дип, тегермәннән атасыны чакырып хат язган иде.

Кыям бабай кызының хатыны алыр-алмас Казанга килеп йеткән иде. Кыям бабай, сала тегермәнчесе генә булса да, дөнья күрмәгән кеше түгел иде. Бай булганга, зур кешеләрдән дә белеше-танышы аз түгел иде. Казанга килгәч, вакыйганы бәйин-бәйин сөйләп биргәч, белеш-танышына барып киңәш итсә дә, Кәримнең бөтенләй гаеплелеге беленгәнгә, котылуыны һичбер кеше сөйләми иде.

Мәхкәмә каршында Кәримнең кеше үтерүе сабит булганга, терелгәч яки каторгага, яки Себергә йебәреләчәк иде. Кыям бабай, ничек булса да, киявене шул бәладән коткарырга теләп, акча тотарга булса да, кызганмаска булып кереште. Алай итсә дә булмады, болай итсә дә булмады, Ахыры билгеле инде, Кәрим үтергән, гүаһлар барысы да әйтеп тора. Сугышларыны башка күрүче булмаганга, һичбер рәт берлән котылдырыр хәл юк иде.

Кыям бабай да, «эзләгән эз табар» дип йөри торгач, тәрәзәдән бунларның сугышларыны күргән кешене тапты. Аның сүзенә караганда, әүвәл Кәримне җыйнаулап кыйнап үтерә башлаганнар, имеш тә, Кәрим үлемнән котылыр өчен генә пәке берлән ярган, имеш. Кыям тегермәнче бу кешедән мәхкәмә берлән соратып, мәхкәмәдә дә шулай сөйләгәч, мәхкәмә Кәримнең зарарындагы шаһидләрне гаепле итеп, Кәрим терелгәч, керсә дә, төрмәгә генә керерлек булган иде.

Сәгыйдә бикә, Бәдрия, Рифгать, Кыям бабай бу эштән котылуларына шатланып, Кәримгә дә хәбәр итәргә, хәл белдерергә барсалар да, Кәримнең телсез-авызсыз, җан бирергә ята торган вакытына тугры килделәр. Фатыйх байның өй җәмәгатьләренә тагы хәсрәт! Нишләсеннәр?.. «Үлгән артыннан үлеп булмый, Алла үземезнең сәламәтлегемезне бирсен» дип, бер-берсене юатып, хәсрәтләрене бастырдылар. Алай да кайгы шулай гына басылырлык түгел иде. Аллаһе Тәгаләнең бәндәләренең күңелләрене рәхәтләндерер,

хәсрәтләрене таратыр, кайгыларыны бетерер өчен биргән күз яше болар өчен кич үткәрергә, вакыт уздырырга ярады.

Кыям бабай хатыны Фәхриҗамал абыстайның да, бердәнбер кызының утыз биш-кырык яшьтә тол калуыны күрүе бик авыр булачак иде. Ләкин Фәхриҗамал абыстай бу вакыйгадан өч ел элгәре үлгәнгә, дөньяның бу хәсрәтеннән татымый калган иде.

Икенче көнне Кәримне ярып күмделәр.

Дөньяның һәр начарлыкларына урын булган, кайгы-хәсрәтләренә йер булган Фатыйх байлар җәмәгате Кәримсез дә торырга өйрәнә башладылар. Алай булса да, һәр кичне кычкырып-бакырып кайта торган кеше булмаганга, кайтыр вакытында утырып җылашалар иде.

Анысы да басылды. Рифгать әбисене җылатмаска хәйлә тапты: ул да—этисенең кайтыр вакыты йеткәч тә Коръән укый башлап, аларны җылатмый калдыру иде.

Кыям тегермәнче дә тегермәнгә кайтып китте.

Бәдрияләр үзләренә бертөрле тормыш берлән тора башлаганнар иде.

Сәгыйдә бикә, намаздан бушанмый торган, кулыннан тәсбихыны төшерми торган бер карчык булды. Бәгъзе ахирәт дуслары хәзрәт сабагына керергә димләшсәләр дә,Сәгыйдә бикә, дәүләтләре юкка, ишан хәзрәтләре янында акча кадерлерәккә, тапшырылырга барырга базмый иде. Ахырдан, барып: «Хәзрәт, үзем картайдым, дәүләтемез юк, ахыр гомеремдә сезнең канат астыңызга керергә тели идем», — дип, сабакка утырырга теләсә дә, ишан хәзрәт: «Үзең дә карт икәнсең, байлыгың да юк, сездән ни өмет итәргә, ни алырга кирәк!» — дип кабул итмәгәнгә, Сәгыйдә бикә дә: «Мин коры яхшылык — яхшы дип беләм», — дип сөйләп йөри иде.

Рифгать мәктәпне бетергән, дин таныган, дөньяда көн үткәрерлек белемле кеше булган иде һәм русча да бик яхшы укыган, бик күп нәрсә белгән иде.

Кыям бабайның Бәдриядән башка баласы булмаганга, тегермәнче бабайның акчасы, мал-туарлары, барысы да Бәдриягә калып, тагы бер рәхәт

гомер күрәчәкләр иде. Бәдриянең Рифгате, кирәк анасының тәрбиясеннән, кирәк мәктәп өйрәтүеннән тәүфыйклы, әдәпле, инсафлы көенчә генә унсигез яшенә җиткәндә Кыям бабай да вафат булды.

Васыяте буенча хаҗга йебәрү, Казан җәмгыяте хәйриясенә өч мең тәнкә бирү, күрше авылларының мәктәбене карар өчен ике йөз дисәтинә билгеләнгән йерне алудан башка да утыз биш мең тәнкә акча, бер тегермән һәм биш йөз дисәтинә йер калган иде.

Сәгыйдә берлән Бәдрия Кыям тегермәнчене васыяте буенча йерләп, васыятьләрене тутыргач, дөньяны бөтенләй баштан ташлап Рифгатькә бирер өчен, киңәш-уңаш берлән Рифгатьне өйләндермәкче булдылар. Бәдриянең гакыллы хатын икәнлеге беленгән шикелле, Рифгатьнең дә һәрьяктан йетеш булуы үзен халык теленә чыгарган, кеше күзенә күрсәткән иде. Шуның өчен кайдан кыз сорасалар да алачаклар иде. Шулай итеп, Рифгатькә бик яхшы, бай йердән, бик чибәр, әдәпле, инсафлы, укымышлы кыз алып бирделәр.

Бәдрия дә, башка каенаналар төсле: «Мине каенанам бик рәнҗетте, бу да азрак татысын әле!» — димәенчә, «Үзем күргән йетәр инде, балаларым рәхәт яшәсен!» — дип, кулыннан килгәнне айамаенча, аларның рәхәтләренә тырышты.

Яхшылыкка каршы яхшылык, килен дә, «әнкәй», дип өзелеп, хезмәт итә башлады, Рифгать тә, бабасының иске кибетен алып, сату итә башлады. Элегрәк зуррак фатирда торсалар да, бара торгач үз йортларыны алып, дәүләтләрене Фатыйх байдан да уздырдылар.

Сәгыйдә бикә үз баласыннан күрмәгән игелекне никадәр усаллык кылган, зарар иткән килененең баласыннан күрүенә гаҗәпкә калып, рәхәтләнеп гыйбадәтене кылып кына, киленнә җылап-җылап дога кылып, Рифгатьне дә үз баласыннан якын күреп торганда мескинәнең гомере бетеп, дөньядагы рәхәтләрне Бәдрия, Рифгать, яшь киленгә калдырып, теге дөньяга юнәлде.

Бәдрия дә гомерендә күрмәгән рәхәтләрне күреп, ничә еллар баласының балаларыны тәрбия кылып, вафат булды.

Рифгать яшь бикә берлән, балалар атасы булып, рәхәтләнеп гомер сөрделәр.

*Соң*

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Җәнаб* — берәүне олылау йөзеннән әйтелә торган сүз.

*Косур* — кимчелекләр.

*Ислях* — төзәтү.

*Маэл* — эчтәлек.

*Эстәү* — теләү.

*Назыйры гыйбрәт* — гыйбрәт күзе.

*Вакыйгъ* — булучы.

*Мөдһиш* — куркыныч.

*Хәер хаһ* — яхшы теләк.

*Билгакес* — киресенчә.

*Җәнабе хак* — Алла.

*Хәмияте миллия* — милләтне саклау хисе.

*Тәгъбир* — төш юрау, төштә күргәннәр буенча киләчәктәге эшләрдән хәбәр бирү.

*Мәдәд* — ярдәм.

*Айау* — кызгану.

*Бәйин-бәйин* — бәйнә-бәйнә.

*Һавалар* — һавалану, тәкәбберлек.

*Тәрбиятел-этфаль* — яшь балалар тәрбиясе.

*Мороз* — туңдырма.

*Фидаи* — фидакарь.

*Һәвәсләү* — теләү.

*Манзарә* — күренеш.

*Низам* — тәртип.

*Хосус* — очрак, мөнәсәбәт.

*Зикер* — телгә алып узу.

*Әлеп-би ( әлеф, би*) — гарәп әлифбасында беренче хәрефләр.

*Солул изид* — ысулы җәдид.

*Саяк сандырак* — саташкан.

*Исмасам* — ичмачам.

*Фидия* — үлгән кешенең гөнаһсын йолып алу өчен бирелгән мал, йолым.

*Күремле* — гел карап торырлык матур.

*Бине бәшәр* — адәм балалары.

*Кыйсем* — кисәк, өлеш.

*Сәфаһәт* — бозыклык.

*Кабил* — булдыра алу.

*Мәгъсум* — гөнаһсыз.

*Хасыйле* — кыскасы.

*Мотлак* — бары тик.

*Мөнтәкыйзы табигать* — табигать таләбе.

*Мәсгуд* — бәхет.

*Мөхакәмә* — фикер йөртү.

*Хәтем кылу* — укып тәмамлау.

*Сайә* — бу урында тәэсир.

*Ихтыяр кылу* – теләү.

*Мәгъриб зәминдә* — Көнбатыш җирлегендә.

*Мөбаләгә* — күпертелгән.

*Йа афзалы дәр хатран* — күңелем түрендәге яхшылык.

*Фидаәнә* — фидакарьләрчә.

*Ишрак намазы* — кояш чыкканда укыла торган намаз.

*Сөннәт* — гадәт.

*Сафдәрун* — эчкерсез, беркатлы.

*Мөнасәбәте гайре мәшруга* — шәригатькә каршы мөнәсәбәт.

*Димаг* — ми.

*Мөҗәррәб* — сыналган.

*Ганимәт* — бәхет.

*Галәм* — халык.

*Ригал* — кайгырту.

*Зикер* — Алланы телгә алу, "Алла" исемен кабатлау.

*Хиләф* — кире, тискәре.

*Уйсыз* — кайгы- хәсрәтсез.

*Галимҗәнаб, бәлэнд, һиммәтле* — олы күңелле, намуслы, мәрхәмәтле.

*Мәхкәмә* — суд.

*Сабит* — шиксез, ачык.

*Гүад* — шаһит.

**Бай угылы.** — Повестьны басарга рөхсәт С.-Петербургта 1903 елның 13 гыйнварында бирелә. Беренче басмасы кереш мәкалә белән Оренбургта М.-Ф Кәримов типографиясендә 1903 елда чыга. 68 бит Имза: Мөхәммадгаяз әл-Исхакый. Китапның соңгы битендә: «1896— 1897 сәнә, Яңа бистә” дип куелган. Сәгыйть Рәмиев белән Габдрахман Хәсәеневнең «Мөхәммәдгаяз әфәнде» исемле мәкаләсендә Г. Исхакыйның бу повесте Яңа бистәдә мәдрәсәдә укыткан чагында, Татар укытучылар мәктәбенә кергәнче үк язылуы турында әйтелә (Г. Исхакый бу мәктәпкә 1898 елда укырга керә), «..ләкин ул вакытта андый китапларны бастырырга һәвәсле кеше булмаганга, 1903 елга кадәр басылмый кала». *(Китапта: Исхакый Мөхәммәдгаяз. Зиндан. Казан, 1907),*

Әсәрнең икенче басмасы беренче һәм икенче басмаларга кереш мәкаләләр белән Казанда И. Н. Харитонов типографиясендә 1910 елда чыккан Имза: Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый. Г. Исхакыйның «Мәҗмугаи асаре». 1 нче җилд, 4 нче китап, 159 -224 б.б.

Җамал Вәлиди әдипнең беренче чор иҗатына бәя биреп болай ди «Гаяз

эфәндедә без үз халкы илә берлектә үскән, берлектә үсмәктә булган бер халык әдибе күрәмез. Әле ул каләм тотып мәйданга чыккан вакытта татар дөньясы яхшы гына тирән караңгылыкта вә йокыда булып, шуның илә бергә үзләренең тычкан утлары илә шул куе караңгылыкны сыекландыручы һәм шау-шулары илә шул йокының тәмен качыручы берникадәр тынычсызлар ла бар иде. Гаяз эфәнде дә шул тынычсызлар арасына барып кушылды, ул да тычкан уты күрсәтте. Сез карагыз аның иң элекке әсәре «Тәгаллемдә сәгадәт»кә, соңра «Кәләпүшче кыз» илә «Бай утылы»на. Болар никадәр саф диляна вә никадәр әхлакчы! Боларда әле сәнгать бик аз эш күргән. Типлар юк, сурәтләр дә гаять юка булып, алар артында яшеренгән вәгазь иң гади күзгә күренеп тора.. Шулай булса да, ул шул вакытта ук үзенең истигъдатын, табигатен, хөласа Гаязлыгын күрсәтә. Аның язганнарында башкаларда күрелмәгән бер хөлус вә җәдит күреләә. Ул чагында ук милләтнең чын авыруларын карый, зур яраларын күрсәтә, күп сырланмый, фәлсәфә сатмый». *(Гаяз әфәнде. «Вакыт». 1913, 5 март).*

Текст әсәрнең икенче басмасыннан алынды.

*«Аркадия»* — Кабан күленең аргы башындагы бакча. Анда ял итәргә шәһәр үзәгеннән Кабан күле буйлап пароходта барганнар.

*Әбҗәд* — борынгы гыйбрани (яһүд) әлифбасындагы хәрефләр тәртибен күрсәтү өчен ясалган мәгънәсез сүзләрнең беренчесе һәм шул сүзләрнең барысының исеме (бу сүзләр: әбҗәд, һәүваз, хоттый, кәләмән, сәгъфәс, коришәт, сәхоз, зазог. Соңгы икесе гарәпләр тарафыннан өстәлгән). Бу сүзләрдәге тартыклар тәртибе берлеләр, унлылар, йөзлеләрне һәм ахыргы «г» мең санын белдерә.

«*Тәкый гаҗәп»* («Азырзаман»)— татарлар арасында бик күп таралган шигъри әсәр.

*«Фәттахетдин»* («Кыйссаи Фәттахетдин») әкиятләр китабы. Казанда 1881 елда басылып чыккан.

*«Сәед Баттал»* («Кыйссаи Сәед Баттал») - XIII гасыр төрек әдәбияты (фольклоры) үрнәге, тарихи вакыйгаларга нигезләнгән каһарман дастаны.

*«Гуҗ бине Гонык»* — ахыргыманда җир өстенә чыгып, аны кызыл балчыкка кадәр ашап бетерергә тиешле, кеше кыяфәтендәге зур җан иясе турындагы мифологик әсәр.

*«Әбугалисина»* — Ибне Сина Әбү Гали Хөсәен ибне Габдулла (Әбүгалисина, 980 ел тирәсе — 1037) , ислам галәменең философы һәм мәшһүр табибе тирәсендә ясалган ривайәтләргә нигезләнеп терек телендә язылган әсәр. Төрекчә килеш Казанда 1864 елда басылган. 1881 елда Каюм Насыйри татарчага тәрҗемә итеп бастыра. 1900 елга кадәр шул тәрҗемә барлыгы биш мәртәбә кабат басыла.

*Печән базары* — XVIII гасырның икенче яртысында барлыкка килә һәм 1930 елларга кадәр яши. Казанның хәзерге Киров, Париж Коммунасы һәм Татарстан урамнарының шактый өлешен биләп, татар байларының эреле-ваклы кибетләре, складлары, харчевнялары белән беррәттән газета-журнал редакцияләре, «Болгар», «Амур», «Сарай» кебек Г. Тукай, Ф. Әмирхан һ. б. күренекле кешеләр яшәгән кунакханәләр дә урнашкан булган. Татарлар өчен яңалыклар белән уртаклашу, хәбәрләшү үзәге дә булып исәпләнгән бу атаклы базар һәм аның халкы сатучылары, алучылары, гайбәтчеләре, алдакчылары — Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Исхакыйларның әсәрләрендә тәнкыйть һәм сатира объекты булып хезмәт итәләр.

Җамал Вәлиди: «Печән базары дигәч тә гади бер печән сата торган урын дип уйларга ярамый. Анда татарның әдәби, икътисади хәяты тәмәркәз итә. Ул татар тормышының иң җанлы бер сәхнәсе. Анда безнең көленерлек,

хурланырлык йеремез никадәр куп булса, мактанырлык, куанырлык йеремез дә шундадыр. Шуның өчен инде «Печән базары» дигән сүзне һәрвакыт бер истихкар вә истиһза мәкамендә улланудан туктарга вакыт!» *(Бер ел узгач.— Вакыт. 1914, 6 февраль).*

*Ат кәмите* —элек сөйләм телендә цирк, балаган.

*Май кәмите*—«май чабу» дип тә йөртелгән. Рус, чуваш, мари һәм керәшен татарларының яхшы атлар җигеп сәйранга чыгуы белән характерлы булган борынгы бәйрәм, кышны озату бәйрәме (русчасы: масленица). Славяннарның мәҗүсилек дәвереннән калган бу бәйрәмнәрен руслардан да артыграк бер ләззәт белән татар сәүдәгәрләре һәм татар мастеровойлары бәйрәм итәләр, кыш буе көтеп алып, атна буе май чабалар... (Май чабу.—Ф. Әмирхан.— Кояш, 1914, 18 февр.)

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 1 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1998. Б. 113-153.
Текстны әзерләүче: Лена Гайнанова